Сирень Якупова

# Яшәү сере

*Шигырьләр*

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2008

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Я38

**Якупова С.М.**

Яшәү сере: шигырьләр / Сирень Якупова. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2008.— 127 б. — 1000 д. — ISBN 978-5-298-01732-9

Җыентыкка шагыйрәнең фәлсәфи-лирик шигырьләре тупланды.
УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
ISBN 978-5-298-01732-9

© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Якупова С.М., 2008

# Ике гасыр баласы мин...

## Кадерен беләм

Уянам да котлыйм үз-үземне
Яңа туган якты көнем белән.
Төннәр кочагында калганым бар,
Һәр иртәнең шуңа кадерен беләм.

Уянам да котлыйм үз-үземне
Керфегемдә сынган нурлар белән.
Болыт каплый кайчак тормыш күгем,
Кояшның мин шуңа кадерен беләм.

Уянам да котлыйм үз-үземне
Бакчамдагы кошлар җыры белән.
Моң-зарларны, сагышларны җиңгән
Җырларның да бүген кадерен беләм.

Уянам да котлыйм үз-үземне
Яңа туган якты көнем белән.
Җырдан-моңнан, кояш-нурдан торган
Дөньяга мин тик бер генә килгән!

## * * *

Язмыш җиле, шөкер, минем яклы,
Җилкәнем дә ак шикәрдәй аклы.
Гомер дәрьям киңме?
Белгәнем шул —
Ярдан ярга чаклы,
Ярдан ярга чаклы...

Хыялларым таулардан да биек,
Болытларга китә хәтта кереп.

Кайсы чынга ашты?
Буламыни
Болыт аша күреп,
Болыт аша күреп...

Минем дәвам — кызым килә үсеп,
Каләмемнән җырым кала күчеп.
Бәхет җырмы инде?
Кем соң киткән
Яшәү серен чишеп,
Яшәү серен чишеп...

* * *

И түбәннән агылалар бу болытлар,
Уй-түбәмә кагылалар бу болытлар.
Туган йортым...
Менсәм аның түбәсенә,
Бер шигем юк түбәм күккә тиясенә.

Тик күптәннән минем анда менгәнем юк,
Күк күгәрчен балаларын күргәнем юк.
Җил малаен көнләштереп, көлә-көлә,
Кыек буйлап яланаяк йөргәнем юк.
Морҗаларның корымнарын борынымнан
Ничә җәйләр соңгы тапкыр сөрткәнемә?
Ничә көзләр, ничә кышлар, ничә язлар
Туган җирдән еракларга киткәнемә...

И түбәннән агылалар бу болытлар,
Йөрәгемә кагылалар бу болытлар.
...Менсәм дә мин Каф тавының түбәсенә,
Бер шигем юк түбәм күккә тимәсенә.

## Җыр тыңлаганда

Әти башлаган җыру бу,
Әни кушылган җыру.
Ике җаннан бер моң булып
Миңа сузылган җыру.

Өзелмичә ничек чыдар
Күңелнең ятим кылы,
Кушылганда
Әтинең соңгы җырына
Әнинең соңгы җыры...

## Сандыгымда өч күлмәк

Сандыгымда өч күлмәк,
Өчесе дә ап-актан.
Берсе аның — ак биләвем,
Мине төреп йоклаткан.

Челтәр-челтәр читләренә
Бишек җыры чигелгән.
Һәр җөенә әниемнең
Күз нурлары үрелгән.

Икенчесе — ак күлмәгем,
Туй көнем истәлеге.
Буйларымның зифалыгы,
Билемнең нечкәлеге.

Хисләремнең пакьлеге ул,
Уйларымның аклыгы.
Гомерем буйларына җитәр
Мәхәббәтем сафлыгы.

Өченчесе — ак кәфенлек,
Минем соңгы күлмәгем.
Ак килеш китү дөньядан
Минем соңгы теләгем.

Сандыгымда өч күлмәк,
Өчесе дә ап-актан.
Ак биләвем, туй күлмәгем,
Ак кәфенлек... азактан.

## * * *

Мең үлеп, мең туа кеше күңеленнән
Бер мизгелдәй кыска гына гомерендә...

Яз башында шыткан үлән сыман
Хис итәмен бүген үземне.
Әйтерсең лә яңа тудым җиргә,
Яңа гына ачтым күземне.

Аяз күкнең җете зәңгәрлеген,
Кояш нурларының яктысын,
Йолдызларның сихри җемелдәвен,
Серле айның көмеш яртысын

Әйтерсең лә бүген генә күрдем,
Бүген тойдым назын җилләрнең,
Дидем дә мин, рәхәт сулап куйдым
Ләззәтеннән килер көннәрнең...

## Дөнья

Җиңдең, дөнья...
Җибәр, кысма, зинһар, йөрәгемне.
Мин бит хатын-кыз.
Бил алышыр ирләр, илләр барда,
Аларның син әнә билен кыс.

Оттың, дөнья...
Бушайт, өзәсең лә
Соңгы кылын моңлы күңелнең.
Отылуым өчен, сөйләштек ич,

Соңгы сөю белән түлимен.
Җиңдең, оттың, дөнья, тәнне-җанны...
Булдыралсаң, яшә дисеңме?
Кара көйгән иреннәрем, ишет,
Ак дип дәшә синең исемне,
Ак дип дәшә синең исемне...

## Яшим икән әле!

Туар таңны сагынып көтеп алдым,
Алсу нуры бит очыма тамды, —
Яшим икән әле!

Тәрәзәмә җилләр чиертеп узды,
Сайрар кошлар моңлы җырын сузды, —
Яшим икән әле!

Күкрәгенә ярның башым куйдым,
Сокланулы күз карашын тойдым, —
Яшим икән әле!

Хисләремә кушып сөю назын,
Төшемдә дә бүген шигырь яздым, —
Яшим икән әле!

*** * ***

Сиңа гына кирәкме бу дөнья?
Дисең кайчак, мине кызганып.
Азапланма, җитешмәссең барыбер
Һәр карага аклы сүз ябып.

Сиңа гына кирәкме бу дөнья?..
Миңа гына түгел түгелен.
Тик нәкъ бүген мин дөньяга кирәк,
Аңа терәк — моңлы күңелем.

*** * ***

Үз телемдә сүз әйтимче,
И дөнья, колагыңа!
Гомер кыска, җавап көтмим,
Син бары тыңла гына.

Ишет кенә, сикерт кенә
Чал кашыңны, сокланып,
«О бөек Тукай теле!» — дип,
Тәүге аваздан танып...

## Шигырь туган көндә

Туган көнең белән, яңа шигырем,
Ак дөньяга килгән көнең белән!

Иҗат газабында тудың, шуңа
Үз баламдай сине якын күрәм.

Үз баламдай назлап, өмет дигән,
Хыял дигән ак биләүгә төрәм.
Син тирбәлгән күңел бишегемне
Буй җитмәслек йолдызларга элəм.

Һәр авазың, һәрбер сүзең тансык,
Тыңлап туймыйм, кушылып елыйм, көләм.
Бүген миңа күк капусы ачык,
Бәхетнең нәкъ диңгезендә йөзәм.

Туган көнең белән, яңа шигырем,
Ак дөньяга килгән көнең белән!
Шигърияттнең Бөек агачында
Нәни яфрак итеп сине күрәм...

## Мин — гашыйк

Мин тумыштан йолдызларга гашыйк,
Август төнендәме туганга.
Тәүге тапкыр йолдыз яңгырында
Тәпиләрем әллә юганга,
Мин тумыштан йолдызларга гашыйк...

Мин тумыштан чәчәкләргә гашыйк,
Гөл исеменме әнкәм куйганга.
Өй каршында үскән сиреньнәрнең
Сеңелләре әллә булганга,
Мин тумыштан чәчәкләргә гашыйк...

Мин тумыштан җырга-моңга гашыйк,
Күңелемме нечкә кыллардан?
Һәрбер сүзе газиз туган телнең
Яралганга әллә моңнардан,
Мин тумыштан җырга-моңга гашыйк...

Мин тумыштан туган җиргә гашыйк,
Монысы инде, беләм, шуңардан:
Авылымның кизләү-чишмәләре
Сөю белән җаным сугарган,
Сөю белән җаным сугарган...

## * * *

Кышлар озын булган саен
Тансыграк икән яз.
Гомер язы узган саен
Тансыграк икән наз.

Таш сукмактан йөргән саен
Тансыграк йомшак җир.
Давылларны күргән саен

Тансыграк йомшак җил.

Диңгезләрне гизгән саен
Тансыграк туган яр.
Araларны өзгән саен
Тансыграк сөйгән яр...

* * *

Нурларында таңның коенмасаң,
Саф чык булып җиргә сыенмасаң,
Иртәң, димәк, үткән заяга...

Хыялланып күккә карамасаң,
Исең китеп йолдыз санамасаң,
Кичең, димәк, үткән заяга...

Түшләреңә гөлләр кадамасаң,
Чәчләреңне җилдә тарамасаң,
Җәең, димәк, үткән заяга...

Бураннарга кереп адашмасаң,
Язлар диеп һәр көн саташмасаң,
Кышың, димәк, үткән заяга...

Яшь бөредәй көлеп уянмасаң,
Мәхәббәттән янып-көялмасаң,
Язың, димәк, үткән заяга...

Сагышларга әгәр төренмәсәң,
Алтын яфрак булып өзелмасаң,
Көзең, димәк, үткән заяга,
Гомереҥ, димәк, үткән заяга...

* * *

Кыштыр-кыштыр, кыштыр-кыштыр
Көзге яфрак.
Такыялар үрер чак та —
Вакыт таррак...

Шыгыр-шыгыр, шыгыр-шыгыр
Үртәшә кар.
Ачуланыр идем туктап —
Вакытым тар...

Кетер-кетер, кетер-кетер
Кителә боз.
Язгы ташу, йөрәк ярсу —
Ашыгабыз...

Тыпыр-тыпыр, тыпыр-тыпыр
Тамчы бии.
Кушылып бер тыпырдарга
Вакыт тими...

Кыштыр-кыштыр, шыгыр-шыгыр,
Тыпыр-тыпыр итә икән.
Вакыт чиксез, гомер генә
Сизелми дә үтә икән...

## Бәхет

Күлмәклек ефәк сайлыйм:
Кулыма алып карыйм,
Иңемә салып карыйм,
Көзгегә барып карыйм.

Килешсен дим йөземә,
Туры килсен күземә.
Ошасын сөйгәнемә —
Җирдә бер дигәнемә.

Әни киңәшен тотып,
Кисәрмен дога укып.
Җырлый-җырлый тегәрмен,
Көлә-көлә киярмен...

Күлмәклек ефәк сайлыйм,
Иңемә салып карыйм.
Кем ничектер, мин бәхетне
Бүген нәкъ шулай аңлыйм.

## Тәрәзәмә яңа пәрдә элдем

Тәрәзәмә яңа пәрдә элдем,
Алсу төсне кызым сайлашты.
Бу дөньяга алсу пәрдә аша
Карыйм хәзер, күзем җайлашты.

Алсу таңнар икеләтә алсу,
Киң офыклар ята ал булып.
Баш өстемдә йөзә (ни могҗиза!)
Соры болыт түгел, ал болыт.
Үткәннәрем ал томандай эри,
Киләчәгем дәшә — ал рәшә.
Узган яшьлек, сизәм, бүген миннән
Ал көнләшү белән көнләшә.

Ә бит бары яңа пәрдә элдем,
Алсу төскә кызым күндерде.
«Бу дөньяга минем күзләр белән
Кара әле, әни, бер», — диде.

## * * *

Болыт йөзә, болыт ага, дибез,
Димәк, күкләр — диңгез.
Төпсез диңгез, чиксез диңгез...

Айлар ага, еллар ага, дибез,
Димәк, вакыт — диңгез,
Төпсез диңгез, чиксез диңгез...

Уйлар ага, моңнар ага, дибез,
Димәк, күңел — диңгез,
Төпсез диңгез, чиксез диңгез...

## Күңел эзли

Ябык ишекләрне тырмый-тырмый,
Җылы эзләп йөргән мәче сыман,
Ышыкланыр урын эзли күңел
Заман җилләренең әчесеннән.

Ышыкланыр урын эзли күңел
Гомер күзләремнең яңгырыннан.
Чакырса да өзелеп яшьлек язым,
Күперләр шул күптән яндырылган...

Ышыкланыр урын эзли күңел,
Алда салкын кышым бит инде.
Гомерем буе җирдә урын эзлим,
Күккә ашар өчен беркөнне...

* * *

Талчыбыкны бөгә-тезә,
Каз оясы үрә идек.
Шул ояга ана казның
Сөенгәнен күрә идек...

Киртәләрне сүтә-тезә
Кордык тормыш оябызны.
Шул ояга сөенергә
Әниләр юк, шуңа моңсу...

* * *

Йөгермәдем, ашыкмадым бер дә,
Ләкин йөгергәннәр белән бергә
Килеп кердем сары көзгә.

Моңсу гына башым салып,
Торам менә уйга талып,
Булмый икән көзләреңә
Соңга калып...

* * *

Качышлы уйныйм үткәннәр белән,
Мең кат уйналган, бик таныш уен.
Тик...
Качуы кыен, качуы кыен...

Табышлы уйныйм көткәннәр белән,
Бер уйналмаган бик серле уен.
Тик...

Табуы кыен, табуы кыен...

Кайчакта уйлыйм: нигә соң уйныйм?
Бүгенгемә, дим, йөрәгем, сыен.
Тик үткәннәрсез һәм көткәннәрсез
Яшәве кыен, яшәве кыен...

## Ромашкалар

Юл читендә ап-ак ромашкалар,
Көз уртасы инде югыйсә.
Быел кышлар булмас, ахры, дигән
Уйларымны шундук җил кисә.

Тәнгә үтеп, җанны өтеп исә,
Ә чәчәкләр ничек түзәдер?
Хәзер гөлләр чыдамрак мәллә?
Җан-тәннәр дә, бәлки, үзгәдер...

Ә без...
Ә без бигрәк бәллүр канат идек,
Нечкә күңел идек, хис тә моң.
Хыяллардан үрдек ал бишеген
Гел еларга торган дөньяның.

Ромашкадай ак күлмәкчән генә
Килеп кердек аннан көзләргә.
Туңдык, шиңдек, егылып калды кемдер
Заман салган баткак эзләргә...

Юл читендә җәйнең ак гөлләре,
Көз уртасы инде югыйсә.
Ап-ак килеш ап-ак кышка кергән
Өметләрне, зинһар, җил, кисмә!

## Таган

И арыды канатларым,
Очам диеп талпынып.
Ә очуым булган икән
Тик... таганда атыну.

Кызыгып, читтән көнләшеп
Күзәткәндер балалар:
«Их, без дә бер очар идек,
Бушаса шул таганнар!»

«Кайчан җиргә төшәр?» — диеп
Көрсенгәндер дусларым.
Тилегә тиңләп, үчекләп,
Бер көлгәндер дошманым.

Тик мин генә беркемне дә
Ишетмәдем, күрмәдем.
Җилләрдә торды җилфердәп

Ак чәчәкле күлмәгем.

Бүген кинәт очып төштем
Хыялым таганыннан.
Үткән елларым агалар
Яшь булып яңагымнан...

## Бер үпкәм юк

Бер зарым юк сезгә, и кешеләр!
Бер үпкәм юк сиңа, и дөнья!
Өлешемә тигән көмешем, дип,
Һәр сукмакка әйттем, һәр юлга.

Абынсам да бик еш, егылсам да,
Еласам да шуңа үкереп,
Чит-ят күзләр күреп өлгергәнче
Тора алдым һәрчак сикереп.

Пыскып янган өмет кисәвен дә
Йөрәгемә төреп саклалым.
Беркайчан да үзем өчен генә,
Каен кисеп, учак якмадым.

Балачакны баллы чәчәк дидем,
Яшел таҗым дидем яшьлекне.
Саф чишмәле гомер җәйләремдә
Кушучлап гел эчтем бәхетне...

Көзләремә, кышларыма керәм,
Эзләремне күмәм җыр-моңга.
Бер зарым юк сезгә, и кешеләр!
Бер үпкәм юк сиңа, и дөнья!

### * * *

Ничә тапкыр җиргә килдең, җаным?
Мин ничәнче синең чәчәгең?
Ничә гомер күбәләктәй көйдең,
Ничә гомер яздай яшәрдең?
Картмы соң син, әллә бик-бик яшьме?
Җаннар арасында ни бәяң?
Гөнаһларга чумган бу дөньяга
Зурмы, җаным, үпкә-кинаяң?
Аһ, ник сорыйм?
Күрәм, тоям, янам —
Синең газап — минем газап ла...
Яшим мәллә шулай янып-көеп,
Соңгы төнең булып, азакка?
Кабат җиргә кайтмасыңны белеп,
Кабатланмасымны үземнең?..
Ал син, җаным, ал син мәңгелеккә
Мине түгел,
Тик авазын шигъри сүземнең!
Һәм... ышандыр кабат кайтырыңа,
Туган телнең чәчәк атарына,
Туган җирнең күкрәп ятарына,
Бәхетлеләр генә артырына,

Йомдырганда Ходай күземне...

* * *

Тормыш юлы — ефәк җеп ул
Кул эше белгәннәргә.
Җитеш кенә, дөнья, басып
Без чиккән келәмнәргә!

Тик... ялгыш та басма җанга,
Очса да түбәннәргә...

* * *

И кешеләр, бармы шатлыгыгыз?
Уртаклашыр идем, әгәр булса.
Көләр идем, биер-җырлар идем,
Елар идем үксеп, күңелем тулса.

Һай, белсәгез, нинди рәхәт елау
Йота-йота татлы шатлык яшен!
...Үз кайгымны эчкә йота-йота,
Мин сезләргә бәхет теләп яшим,
И кешеләр...

## Җәйге уйлар

Бәхетле син, күңел!
Һәр иртәне
Тәгәрисең чыклы үләндә.
Канат җиле белән назлый-назлый,
Күбәләкләр оча тирәңдә.

Чикерткәләр синең колагыңа
Төннән откан көйне көйлиләр.
Берсен-берсе бүлеп, җәй гөлләре
Чәчәк ату серен сөйлиләр.

Ай-ваеңа карамыйча, кояш
Сала сине алтын бишеккә.
И тирбәтә, и тирбәтә көлеп,
Яшь баладай күреп, үчекләп.

Онытасың шулчак мин барлыкны,
Моны эшләү, хәер, җиңелдер.
Асфальт юлдан шак-шок басып килгән
Мин түгел ул, әйе, түгелдер...

## Өшү

Кышның соңгы салкыннары...
Язнукылар — чиратта.
Җәй дә гел-гел җылы булмый,
Көз суыта чынлап та.

Яшьлек кайнарлыгы белән
Үткәннәре үтелде.
Бүген әйтерсең күңелнең

Соңгы миче сүтелде.

## Исәнлектә күрешергә язсын

Исәнлектә күрешергә язсын —
Бу теләктә күпме өмет бар!
Исәнлектә күрешергә язсын,
Иртәгәсен явар юеш кар.

Исәнлектә күрешергә язсын,
Яз җилләре, сезнең белән дә.
Кояш нурын кушып наз эчәрбез
Тузганактан алтын келәмдә.

Исәнлектә күрешергә язсын,
Ал чәчәкле җәйге мут алан.
Мин генәме синнән исергән дә,
Син генәме миннән ут алган?!

Исәнлектә күрешергә язсын,
Шагыйрь көзнең моңлы һавасы.
Ефәк җебе булып пәрәвезнең,
Их, бер синдә эленеп каласы!
Исәнлектә күрешергә язсын —
Бу теләктә күпме өмет бар!
Исәнлектә күрешергә язсын,
Куллар биреп көлешергә язсын,
Еллар, айлар, көннәр, минутлар...

## Балалар уенын күзәткәндә

Йомшак уенчык — этләр, песиләр.
Каты уенчык — танк ишеләр.
...Каты-йомшакка дөнья бүленгән:
Каты бәгырьләр, йомшак күңелләр.
Балалар әле моны белмиләр...

Кызлар кулында матур курчаклар,
Ә малайларда — җил җитез атлар.
...Ир-хатыннарга дөнья бүленгән:
Ир — тормыш аты, хатын — дилбегә.
Тик балаларга әле бу нигә?

Алар уйнасын онытып дөньясын...

## * * *

Җир — Кояшның кызы. Мин — Җирнеке.
Кояш миңа әби буламы?
Һәр иртәдә көлеп һәм иркәләп
Чәчләремнән сыйпый шуңамы?

Җир — Кояшның кызы, зәңгәр күзе,
Төрелгәндер сөю нурына.

Чиксез еллар Галәм упкынынннан
Саклый аны шушы нур гына.

Җир — Кояшның кызы, мин — оныгы.
Икебез дә очар күбәләк.
Бәхетлегә дөнья түгәрәк дип
Әйләнәбез Кояш тирәләп.

*** * ***

Бер хакым юк халкым телсез диеп,
Җирсез диеп шигырь язарга.
Тик хакым бар һәрбер татар җанын
Туган телгә төреп назларга.

Тик хакым бар туар һәр иртәгә
Үз телемдә сәлам бирергә.
Ата-бабам яткан изге җирдә
Горур яшәп, горур үләргә
Бер хакым бар!

## Ике гасыр баласы мин

Ике гасыр баласы мин,
Ике гасырныкы да.
Йөрәкне җылыткан учак —
Ике гасыр уты да.

Ике гасыр баласы мин,
Булмадым үгиләре.
Ике бит алмам очыннан
Яратып үбүләре.

Ике гасыр баласы мин.
Икесе бердәй итеп
Татар сүзен пышылдады,
Тылсымлы сердәй итеп.

Ике гасыр баласы мин,
Бәхетсез түгел, түгел!
Ике гасыр — бер вакытның
Күгендә һаман күңел.

*** * ***

Шагыйрь күңеле — җәйге яңгыр,
Буранлап ява, яуса.
Хис-тамчылар шашып бии,
Акыл ышыкка кача.

Җәйге яңгыр — шагыйрь күңеле,
Күкрәүләр аша иңрәү,
Ышыкка качкан дөньяны
Сискәндерергә теләү.

*** * ***

Бураннарын кышның яратканнар,
Җил-давылын якын күргән җәйнең,
Ишетегез!
Бүген сезнең өчен
Шаулы бер җыр җырлап үткән мәлем.

Үпкәләмә, зинһар, тыныч иртә.
Сандугачым, гаеп итмә мине.
Бар тавышка шашып бер җырламый,
Ничек итеп җирдән китим инде?

Кем колагын япсын, күзен йомсын,
Кемдер әйтсен көлеп: «Исәр...» — диеп.
Мин барыбер бүген җырлап үтәм,
Телисезме, аннан китәм биеп?

Җан иреге тәнгә, телгә күчеп,
Үз-үзеңнән хәтта азат булу
Гомергә бер килә торган мизгел —
Бәхеттерме, әллә газапмы бу?

Ләкин, беләм, нәкъ шул мизгел өчен
Туадыр ла шагыйрь бу дөньяга!
Бар тавышка үз телендә җырлап,
Буран-давыл булып күкләр урап,
Үз җиренә ятып тынарга...

# Ана телем

Тугры сүзле горур мишәр халкы —
Татар милләтенең асылы.
Бу бәяне сиңа бирде икән
Чал тарихның кайсы гасыры?

Гөрләп торган Биләр ягыннан мин,
Җырлап торган мишәр ягыннан.
Булыр микән миндәй шушы якны
Янып сөйгән, өзелеп сагынган.

Булыр микән миндәй горурланган,
Мишәрчә сүз укып шигырьдә.
Кандалыйлар, Туфаннарга якташ
Мишәр кызы бит дип үзем дә.

Исхакыйлар, Иманиләр теле
Минем дә дип газиз туган тел.
Һәр авазы аның, һәрбер сүзе —
Йөрәк түрендәге шиңмәс гөл.

...Саф чишмәнең суы тәмле, беләм,
Кизләүнеке барыбер татлырак.
Хуш ислерәк әпәй мең күмәчтән,
Ызба да бит өйдән яктырак...

И туган тел!
Бары синең аша
Тоям ямен, тәмен тормышның.
Булырсыңдыр мине юатучы,
Алган чакта соңгы сулышым.

Исхакыйлар, Имәниләр теле,
Туфаннарның шигъри догасы
Ана телем — затлы мишәр теле,
Халкымның син алтын мирасы!

## Яфрак оча

Нәрсә булды икән бу дөньяга,
Табигатькә, күзгә һәм... безгә?
Саргаеп та әле өлгермәгән
Яфрак сыман өзеләбез лә.

Күз башыннан яуган кар өстендә
Басып калдык җәйге күлмәктән.
Кызгануны белмәс заман җиле
Усал эттәй йолкый итәктән.

Кар аралаш яшел яфрак оча,
Дер калтырый каен кызлары.
Һич төзәлмәс йөрәк ярасының
Үзәкләргә үтте сызлавы...

Асты өскә килгән бу дөньяның
Йөрәкләрдә юк шул бер гаме.
Кар аралаш яшел яфрак оча —
Кемнең кемгә соңгы сәламе?!

*** * ***

Ил казаны кайный дөбер-дөбер,
Чәчрәп-чәчрәп чыга кайбер милләт,
Кул-аягын өтеп хуҗаларның
Һәм ишетеп сүгенү, янау, ләгънәт.

Ил казаны кайный дөбер-дөбер,
Шайтан үзе утын өстәп тора.
Зур калҗалар өмет итеп, читтә
Бүре туе һәр кич өстәл кора.
Ил казаны кайный дөбер-дөбер,
Телләр, диннәр, каннар, җаннар кайный.
...Тәмугларны гына белгән халык
Алырмы соң оҗмахларны таный?!
(Ярый әле бу дөньялар фани...)

*** * ***

Бишекләрдә тирбәлмәгәч,
Каян килсен балага моң?
Тал бишеккә салмак булам
Инде үсеп буйга җиткән
Балаларын замананың.

Тал бишеккә салмак булам
Замананың үзен, көйләп.
«Борын-борын заманда...» — дип,

Якты матур әкият сөйләп.

Тал бишеккә салмак булам
Бүгенгесен татарымның,
Киләчәген күрер өчен
Татар моңлы Ватанымның.

Тал бишектә калмак булам,
Сабый бала — шигъри күңел.
«Әллүки»дән уянган җан
«Әллүки»гә йомар күзен...

* * *

Базарларны җенем сөйми
Нигәдер.
Алыпсатар бабам каны
Кемдәдер?
Миндә түгел. Күрәм, акмый
Баламда да.
...Кыен сатмау-сатылмаулар
Җанын сатар заманада.

* * *

Каравыл! Талыйлар, талыйлар!
Караңгы почмак ла дөньясы.
Ничекләр үткәннән көткәнгә
Бер якты тәрәзә уясы?

Каравыл! Талыйлар, талыйлар!
Буш кесә мең тапкыр кагылган.
Йә малың, йә җаның...
Җан саклап,
Илсез дә, җирсез дә калынган.

Каравыл! Талыйлар, талыйлар!
Даулыйларниләрдер һаман да.
Белмиләр
Талап та баеплар булмасын
Бу рухи хәерче заманда...

* * *

Кара күзлек күзендә,
Усал битлек йөзендә.
Киң эшләпә башында
Төшеп тора кашына.
Күн пәлтә җиргә тия,
Үкчәләр юлны төя...
Йә Ходаем! Кем соң бу?
Җен-шайтанмы? Тфү, тфү, тфү...
Чак таныдым — замана!
Үзгәргән лә соң, кара!
Ярый ла узып бара,
Ә дөнья, шөкер, кала.

* * *

Күңелемдә — таулар биеклеге.
Татар бөеклеге — канымда!
Биеклектә туган уй-хисләрем
Шигырь булып кайный җанымда.

Замананың үткен пычаклары
Тиеп киткән саен тамырга,
Канга манчып сүзләр ата йөрәк,
Тиңләшерлек утлы лавага.

Көл итәм дип килмәдем мин җирне,
Гөлләр итү аны бар уем.
Нишлим, нишлим?
Биш гасырлар элек
Башланган ла икән бу уен.
Биекләрне һәм дә бөекләрне
Юк итүгә корган уеннан
Күптән уймак чыккан, күпме татар
Киселгән дә икән, суелган...
Ә мин исән! Тәңрем саклап калган
Бер бөртеге газиз халкымның.
Тамырыма балта төшкән чакта,
Мескенләнеп елап ятыйммы?

Канлы шигырем бусын палач күзен,
Мирас булсын җаным татарга!
Күңелемдә — таулар биеклеге,
Таудан биек өмет Ватанга.

* * *

Берәм-берәм буар елан йота
Дер-дер килгән мескен куяннарны...
И татарым, елан күзләреннән
Күзләреңне алыр хәлең бармы?

Беләм, авыр, хәтта мөмкин түгел
Карышырга сихри кара көчкә.
Йә Ходаем!
Үз аягың белән
Тере килеш керү утлы мичкә
Язганмыни, халкым, сиңа да бер,
Югалулар эзсез язганмыни?
Куян белән Барс арасында
Аермалар бүген азданмыни?

Чытырдатып йом да күзләреңне,
Ачып җибәр зәңгәр күккә төбәп!
Еланнарга азык булу язык,
Меңьеллыклар кичкән исән милләт!

* * *

Казанны күрергә барабыз,
Бизәнгән, төзәнгән Казанны.
Таптауга-мактауга, зурлауга-хурлауга

Меңьеллар түзәлгән Казанны.

Казанны күрергә барабыз,
Юк кына йомышны бар итеп.
Үзем дә сизмәстән, күр әле, җиккәнмен
Күңелнең атларын пар итеп.

Казанны күрергә барабыз,
Без — аны, ул безне танырмы?
Чорларның чормасын актара милләтем,
Тирбәлгән бишеген табармы?

Тузанын каккалап, төзәтеп сиртмәсен,
Эләрме киләчәк түренә?
Бәйрәмгә дип түгел, мәйләргә дип түгел,
Барабыз Казанны күрергә!

*** * ***

Чишмә — җирнең шатлык яше,
Диңгез — кайгы яшедер.
Шатлык эчәбез югыйсә,
Ник гел сыктап яшибез?

Диңгезләр эзләп китәбез,
Тозлы су — ләззәт, табыш...
Җир шатлыгына сөенми,
Җир кайгысына көенми
Яшәүдә безнең ялгыш.

## Җирем минем

Җирем минем,
Ак төсләрең
Көннән-көн кими синең.
Каеннарың да күлмәген
Ак килеш кими бүген.

Болытларыңның акларын
Карасы куып узган.
Яңа яуган ак карыңа
Кай ара кунган тузан?

Алмагачлар, шомыртларың
Соры шәлләрен япкан.
Аккош күлләрең өстенә
Күксел томаннар яткан.

Җирем минем,
Ак төсләрең
Көннән-көн кими синең.
Каеннарың да күлмәген
Ак килеш кими бүген...

Күңел күзебез аклыкны
Күрми башлады мәллә?
Ак канатлы фәрештәләр

Безне ташлады мәллә?..

* * *

Кояшлы кар ява. Җир өстендә
Алтын белән көмеш аралаш.
Кышлар туйлый, дөнья туйлый бүген,
Әйтерсең лә кәләш һәр агач.

Күкнең күзе ярый кара түгел,
Көнләшүдән азмы үлүчеләр?
...Сөбханалла, җирем, сөбханалла!
Һәм мең гомер кадерең белүчегә,
Матурлыгың синең күрүчегә.

## Эт язмышы

Җил-яңгырдан качар оясы бар,
Ашыйм дисә — ашы, сөяге.
Саклыйм дисә, усал хуҗасы бар,
Бар әлегә аңа кирәге.

Бар барлыгын юктан юк итүче
Чылбыры бар тагын муенда;
Урам диеп бер ыргылса, мескен,
Калын чылбыр тәнгә уела.

Эт язмышы... Әй лә, ил язмышы
Тынгы бирми күңел-уема.
Ирек диеп бер талпынса халкым,
Канлы чылбыр җанга уела...

* * *

Кызган мунча ташы кебек
Чыжылдап тора җаным.
Кайнар җанлы, кызу канлы
Татар бардыр бит тагын?!

Кушылыгыз минем җанга,
Бирегез кулыгызны!
Эретик милләтне баскан
Ничә гасырлык бозны.

Калсак калыйк су астында
(Боз катламы, ай, калын...),
Татар Атлантидасы бер
Тетрәндерсен Җир шарын.

* * *

Сугыш бара илдә, кан коела.
Үз халкына каршы илбашы.

...Таулар тыныч, таулар шундый тыныч,
Кеше җанын изә үч ташы.

Таулар тыныч, алар шундый тыныч,
Таңнар гына шартлап уяна.
...Яши алмас мәңге карга-чыпчык
Тау бөркете корган ояда,
Мең гасырлык горур кыяда!

Бу — хакыйкать! Аңлар өчен шуны
Ике башлы булу җитмиме?
...Йә тол итә халкын, йә кол итә.
Тап бер сәбәп аклар бу илне.
Таулар тыныч, таулар әле тыныч,
Вулканнары атмас бер, димә.
Гөнаһ тотар, кара упкын йотар,
Вакыт дәрьясында ил-көймә.

*** * ***

Бөркетләр тауга оялый,
Мин бөркет түгел, димәк.
Минем җанга иксез-чиксез
Дала киңлеге кирәк.
Колач җәеп очар өчен
Уй һәм Моң канатында,
Туу белән Үлем дигән
Офыклар арасында...

# Әйтә алырбызмы?

Таш түшәлгән сукмак уртасында
Каен кызы үсә шатланып.
«Бу сылуны саклап калдым мин», — дип,
Яшь төзүче сөйли мактанып.

Матуркайны яклап түрәләргә
Каршы чыккан, кушкач вөҗданы.
Быел яз да яфрак ярыр каен,
Яшел ямьгә төреп дөньяны.

Быел яз да сәламләр ул безне,
Яшермичә шатлык яшьләрен.
Сандугачлар җырын тыңлый-тыңлый,
Җил иркәләр ефәк чәчләрен.
Юллар, өйләр таштан булса булсын,
Ташка әйләнмәсен йөрәкләр.
Кисмик әле, кисмик каеннарны,
Алар безгә бик тә кирәкләр.

Таш түшәлгән сукмак уртасында
Каен кызы үсә шатланып...
Җиребезне саклап калдык, диеп
Әйтә алырбызмы мактанып?
Әйтә алсак иде мактанып!

## Танышыма

Сүз табалмый тилмерәсең менә
Үз телеңдә җөмлә төзергә.
Сөйләшәсең, хәтта уйлыйсың да,
Татар кызы, урыс телендә.

Туган илеңдә бит, читтә түгел,
Тукайларны укып син үстең.
Авылыңдагы изге чишмәләрнең
Җырын тыңлап, суын син эчтең.

Яшьлек язың шау чәчәктә чакта
Кырау төште мәллә күңелеңә?
Газизләрдән газиз ана телең
Алыштырдың читләр теленә.

Сүз табалмый тилмерәсең менә
Үз телеңдә җөмлә төзергә.
Телсез калган кошлар җырлый алмый,
Кайтсалар да туган җиренә.

## Китә алмыйм

Сине бүген заман чоңгылында
Батып барган кораб дисеннәр.
Китә алмыйм, Чаллы, сине ташлап,
Киталганнар, әйдә, китсеннәр.

Җилләрнең дә синдә иң зәһәре,
Иң хәтәре исә дисеннәр.
Китә алмыйм, Чаллы, сине ташлап,
Хәтәр җилләр иссә иссеннәр.

Чакырсыннар ерак, чит җирләргә,
Анда оҗмах вәгъдә итсеннәр.
Китә алмыйм, Чаллы, сине ташлап,
Җүләр диеп миннән көлсеннәр.

Бер кайтыр бу туган нигезгә, дип,
Якыннарым өзелеп көтсеннәр.
Китә алмыйм, Чаллы, сине ташлап,
Алар мине гафу итсеннәр...

## Җилләр иле

Җилләр иле дала иде,
Бүген монда кала инде.
Урамнары киң һәм иркен —
Кешеләр дә, җил дә йөрсен.
Ниятебез изге иде,
Аңламады дала җиле.
Риза түгел үзгәрешкә,
Бәгырьләрне телә-кисә,

Көнен-төнен ярсып исә.
Җәен исә, кышын исә,
Язын исә, көзен исә.
Ни кылырбыз, калабызда
Җилкуар бер буын үссә?
Әллә безнең хата инде
Басып алу җилләр илен.
Тынгы юк, дип, күңелләрдә
Үпкәликме соң җилләргә?!

* * *

Сандыгым юк. Әгәр булса да, ул
Буп-буш торыр иде моңаеп.
Сандыкларда саклар күлмәгем юк
Һәм... булмас та инде, мөгаен.

Сандыкларда саклар бизәгем юк,
Үз кулымнан төшкән, җанымнан.
Алдандыңмы диеп, хәйлә белән
Заман карый базар ягыннан.

Кая инде хәзер сөлге чигү,
Ак төслесе өйдә калмады.
Буяу сеңгән чуар зур сөлгеләр
Ак тәннәрне, аңны ялмады.

Чәчләр кыска...
Көмеш чулпы чыңы —
Соңгы җыры гына хәтернең.
Сандыгым юк. Саклар байлыгың юк,
Кичер мине, кызым, кадерлем.

## Язгы буран

Язгы буран адаштырмый, беләм.
Язгы буран саташтыра бары.
Ак чәчәкләр ди бит әнә күңел
Иңнәремә яуган ап-ак карны.

Йөрәк ачык, өстә җиңел кием,
Кар салкыны үтә үзәгемә.
И табигать, салма бозлы караш
Бөреләрнең яшел күзләренә!

Мине сына, минем җанны өшет,
Мин ышанам әле түзәремә...

## Әйләнәм дә кайтам

Әйләнәм дә кайтам еллар аша
Балачакның ерак кышына.
Кыйблабызга багып, кунак әби
Укыган иде намаз пышылдап.

Сәер иде һәр ым-хәрәкәте,
Серле иде әйткән сүзләре.
Пәрдә артындагы тулган айдай
Нурлы иде аның йөзләре.

Ә соңыннан, төенчеген чишеп,
Ачты да ул ипләп китабын,
Күңелләрне күккә ашырырдай
Сихри моңга чумды өй тагын.

Күзем йомып, җылы мичкә сыенып,
Тын да алмый тыңлап утырдым.
Коръән моңы иңгән шушы кичне
Нәни йөрәгемә тутырдым.

Кайда гына йөртмәсен лә язмыш,
Әйләнәм дә кайтам шушында.
Туган йортның һәрбер бүрәнәсе
Намаз укый сыман пышылдап.

* * *

Китәргә җыенган кошлар
Туган илләрдән,
Канат сыный кабат-кабат
Салып җилләргә.
Китмәүчеләр дә кушыла,
Кирәк ул сынау.
Илдә булсын, читтә булсын,
Иң мөһиме —
Канатың сынмау.

## Туган йортым

Бу кадәрле якын булыр икән
Гади генә авыл ызбасы!
Туган йортым,
Син — Мәккәсе җанның,
Күңелемнең изге кыйбласы.

Дөньяга мин синдә аваз салдым,
Синдә оттым тәүге догамны.
Пар тәрәзәң аша танып белдем
«Тормыш» дигән серле урамны.

Шул урамнан атлыйм айлар, еллар,
Синең нурың юлым яктырта.
Синең җылың салкыннардан саклый,
Көч-дәрт бирә хәер-фатихаң.

Туган йортым — татлы бишек җырым,
Туган йортым, анам назы син.
Сандугачлы балачагым җәе,
Кабатланмас яшьлек язым син.

Бар хисләрем, бар рәхмәтем сиңа,
Туып үскән нәни бер оям.
Киң дөньялар кысан, тар чагында
Сиңа әле һаман мин сыям.

*** * ***

Капка киләсен ачарга
Буй җитмәгәннән түгел,
Койма астыннан шуышып
Урамга чыкты күңел.

Алай җайлы, алай тизрәк
Кайтуы балачакка,
Диде дә китте йөгереп
Бал чагым рәшә-чатка.

Борылып кулын изәде,
Хушлашты, әллә дәште.
Капканың эчке ягында,
Хатирәләр кочагында
Үкседем сөртми яшьне...

## Язгы кояш

Язгы кояш,
Хәтерлисең микән мине —
Нурларыңнан качып үскән кыргый гөлне?
Онытыңмы? Һич үпкәм юк, гаеп миндә,
Кояшта да таплар күргән яшьлегемдә.

Язгы кояш,
Ә син шундый шаян идең!
Бар җирдән дә эзләп мине таба идең.
Үбә идең битләремнән, муенымнан,
Әрсезләнеп керә идең куенымa.

Әй, яратмый идем лә соң назларыңны,
Җирән чәчле һәм сипкелле язларыңны.
Күз яшемне көзгем генә күрә иде,
«Җүләрем», — дип юата да көлә иде.

Язгы кояш,
Таныйсыңмы бүген мине?
Синең бүләк-сипкелләрем юк бит инде.
Балачагым, яшьлегем дә китте үтеп,
Ярый син бар юатырга назлап, үбеп...

Язгы кояш!
Быел язда кабатланмас микән тагы
Гомеремнең нурларыңдай алтын чагы?

*** * ***

Сукыр лампа яктысында

Укыган китапларның
Өтере дә истә калган.
Хәтере ул чакларның —
Хәтер дисәң дә хәтер!
...И балачак, балачак —
Үз-үзеңә сөйләп туймас
Гомерлек әкияттер...

*** * ***

«Алтын белән таш ватасың!» —
Дигәч күрше әбием,
Ак тешләремне күрсәтеп
Елмаеп көлгән идем.

Алтын миңа каян килсен,
Теш — сөяк, алтын түгел.
Чикләвек таш була диме,
Ярыла шундый җиңел!

Мең хаклы булган ла әби,
Бүген менә бик аңлыйм.
Алтыннан койган теш белән
Ипи дә ваклый алмыйм.

## Кычыткан

Кычыткан өзәм даруга,
Кулым түзә чагуга.
Бармаклар ни, йөрәгемнең
Уттай янган чагы ла...

Туган авылым кычытканы,
Пешер хәтерне, пешер!
Ялантәпи балачакны
Елатып искә төшер.

Искә төшер яшьлегемне,
Атам-анам каберен,
Туган җирнең, туган телнең,
Туганнарның кадерен.
Онытканны, югалтканны —
Барын да искә төшер.
Туган авылым кычытканы,
Пешер җанымны, пешер!

## Кайту

Туган җиргә — үз җиремә кайттым.
Рәхәтлеге шушы кайтуның!
Арган йөк атыдай, тугарылып,
Болын түшәгендә ятуның!

Җанны ярып үлән исе керә,
Чәчәк төсе тула күзләргә.
Җилфер-җилфер күбәләкләр куна
Чыктан юешләнгән тезләргә.

Күк гөмбәзе зәңгәр чыбылдыктай,
Болыт-болыт ап-ак бизәкле...
...Тамырлардан ага ләззәт-ташкын,
Туктатырдай булып йөрәкне.

Үз җиремә, үз-үземә кайттым,
Китүләр юк кабат диялмыйм.
Дөнья көтә, мин дә дөнья көтәм,
Үз-үземә һич тә сыялмый.

*** * ***

Кышның аяз кичләрендә
Туган авылым өсләрендә
Җирдән йолдызга ара
Чиксезлеккә кыскара.
Йолдызлар түбән төшәме,
Күңел ашамы күккә,
Белмим.
Кемдер җем-җем иткән
Юрган яба да өскә,
Салып ләззәт бишегенә,
Җанны аерып тәннән,
Оныттырып вакыт чиген,
Аралап юк-бар гамьнән,
Тирбәтә генә, тирбәтә
Балачак җырын көйләп...
Кышның аяз кичләрендә
Туган авылым өсләрендә
Бәхеттән балкып нур чәчә
Әллә ай, әллә йөрәк...

## Йөрәк мичем

Йөрәк мичем тартмый.
Моңлы төтен
Чыгар юлын тапмый,
Тын-сулышны каплый.
Күзләремә кереп,
Әрнеп, әчеттереп,
Тик зар булып саркый...

Йөрәк мичем тартмый.
Әллә димен
Яшәп карыйм якмый?
Һай, дөньялар суык...
Бер көн якмасам да,
Күңел өемдәге
Гөлләр үләр туңып.

Тартмый йөрәк мичем.
Әни, киңәш бирче?
Син бит мичче идең,
Син бит көчле идең,

Син бик хисле идең,
Гел күкләрне сөйдең...

Мин дә күккә багыйм?
Җан-морҗамны барлыйм?

Йә Ходаем! Кара!
Кайчандыр ак җанга
Оялаган карга!
Мичче кызы, имеш.
Онытканмын ласа,
Күтәрелү кирәк,
Күтәрелү тиеш
Сөрем, корым аша
Түбә-кыекларга,
Аннан болытларга,
Җанны пакьләү өчен,
Җанны саклау өчен...

Кичер, йөрәк мичем,
Газаплавым өчен.
Мин бүгеннән мичче!
Мин бүгеннән көчле!
Күңелдәге хисне
Йөз ел, мең ел ягып
Бетерә алмам төсле...

## Дәвам

Газиз әнкәй,
Мин — дәвамың синең.
Нәкъ синеке төсле күзләрем.
Синекедәй атлап йөрешләрем,
Синекедәй уйчан йөзләрем.

Газиз әнкәй,
Мин — дәвамың синең.
Кулларымда синең осталык.
Үз хезмәтем белән көн күрәмен,
Хәер-фатихаңнан көч алып.

Газиз әнкәй,
Мин — дәвамың синең.
Синең уйлар минем башымда.
«Балам!» — диеп өзгәләнеп дәшәм,
Синең тавыш минем тавышымда.

Газиз әнкәй,
Мин — дәвамың синең.
Синең хисләр минем күңелдә.
Шул хисләрне җырга салу өчен
Җитмәс, ахры, ике гомер дә.

Газиз кызым,
Син — дәвамым минем!

## Рәшә

Табигатьне сафландырып,
Күңелләрне шатландырып,
Җәйге яңгыр явып үтте.
Бер болыттан бер болытка,
Бер офыктан бер офыкка
Төсле күпер салып китте.

Чал башымны артка чөеп,
Төшемме бу әллә диеп,
Басып торам исем китеп:
Шул күпердән көлә-көлә,
Ялантәпи йөгерә-йөгерә,
Балачагым килә төшеп!

Кара күмер ике күзе,
Сипкел генә алма йөзе,
Чәчләрендә тасма-җилләр.
Елмаюы шаян, серле,
Ә өстендә аллы-гөлле
Әни теккән җиңсез күлмәк.

«Саумы, — диеп, — балачагым!» —
Бар җиһанга аваз салдым
Һәм тын калдым, җавап көтеп.
Ишетмәдем ләкин җавап,
Көлде кояш миңа карап,
Югалгач та төсле күпер.

Табигатьне шатландырып,
Күңелемне сафландырып,
Җәйге яңгыр явып үтте...

*** * ***

Сабантуйда һәрчак бүләк ала
Беренче һәм соңгы килгән ат.
Мин уртада, мин уртада һаман,
Иңнәремдә юкса жыр-канат.

Беренчегә көчем җитеп бетми,
Соңгылардан үзем көчлерәк.
Бүләк өчен генә иң соң булып
Килмәс өчен дә бит көч кирәк.

Һәр сабантуй гомер елын саный,
Бәйгегә дә берчак кермәмдер...
Тик әлегә
Биеп тора жанда чабышкы ат,
Соңгы булып барыбер килмәмдер!

## Кызыма

Көзге каршысына килеп,
Кашларың җыерасың.
Юри түгел, чынлап бугай
Еларга җыенасың.

Сипкелләреңне санийсың
Бармагың бөгә-бөгә.
Тәрәзәдән язгы кояш
Күзәтә көлә-көлә.

Кояш белән мин дә көләм:
«Алтыным, — дим, — сипкеллем!»
Сипкелле кыз була бит ул
Дөньяда иң сөйкемле!
Мин генә түгел, кояш та
Ярата, димәк, сине.
Битеңдәге сипкелләрең —
Кояшның үпкән эзе.

## Күлмәк тегәм

Әбиләрдән калган йола:
Кызыма күлмәк тегәм.
Түшләренә бизәк итеп
Изге теләкләр чигәм.

Таңнан торып, дога кылып,
Ул күлмәкне кистем мин.
Күңелемдәге иман нуры
Кызыма да күчсен, дим.

Үзем дә үстем әнием
Теккән күлмәкне киеп.
Күбәләктәй оча идем
Көзге каршында биеп...

Күлмәк тегәм бүген менә
Кызыма ал ефәктән.
Бер төенсез җөйләренә
Сөю тама йөрәктән.

## Авылыма алып кайтыр юл

Авылыма алып кайтыр юл —
Юлларның юлыдыр ул.
Һәр чокыры мөлдерәмә
Сагыну тулыдыр ул.

Авылыма алып кайтыр юл —
Юлларның юлыдыр ул.
Аяклар өчен — бормалы,
Җан өчен турыдыр ул.

Авылыма алып кайтыр юл —
Юлларның юлыдыр ул.
Туган йорт тәрәзәсенең
Балкышы, нурыдыр ул.

Авылыма алып кайтыр юл —
Юлларның юлыдыр ул.

Озын да, кыска да түгел —
Гомерем буедыр ул.

## Кара куык

Куык кабарта кызым,
Күр замана баласын,
Күпме төсләр арасыннан
Сайлап алган карасын.

Кабара кара куык,
Балам кочагы тулып.
Йөрәгем — телем-телем,
Ә җаным — сулык-сулык.
Куык һаман кабара,
Әйтерсең лә Җир шары.
Шартлый калса, калачак бит
Аннан кара җил бары...

Куык кабарта кызым,
Әй замана баласы!
Күпме төсләр арасыннан
Үз иткән бит карасын.

Ничек кенә аңлатыйм соң
Дөнья аңа каласын?!

## * * *

Сагынасыңмы авылыңны, әни?..
Куырып ала шушы сүзләр тәнне,
Суырып ала җанның җелекләрен,
Сагынасыңмы авылыңны, әни?

Сагынасыңмы, әни, авылыңны?..
Тау-чишмәгә суга баруыңны,
Суга кушып моңнар алуыңны,
Сагынасыңмы, әни, авылыңны?

Авылыңны, әни, сагынасыңмы?..
Исеменә аның табынасыңмы?
Хат-хәбәрдән балкып кабынасыңмы?
Авылыңны, әни, сагынасыңмы?

Сагынасыңмы, әни?..
Аһ, сорамыйм,
Тик елама гына, тик елама...

## Адашканнар

Тагын бер мәче баласын
Адаштырганнар.
Кайтыр юлын тапмасын дип
Саташтырганнар.
Шәһәр салкын, шәһәр олы,

Ә ул бик нәни.
Кайсы урам, кайсы чат бу —
Аңламый берни.
Җансыз ташлар арасында
Теп-тере йомгак
Колакларны яңгырата
Тавышсыз елап...
Кил әле, кил, җылытыйм бер,
Кер куеныма.
Менә сиңа телем икмәк
Бер туенырга.
Тик шуны бел: җылы кочак,
Сый да гел булмас.
Яшим дисәң, үзегезчә
Тырыш син, тырмаш!
Сорама ла, ничек диеп
Өйне табасы?
Мин үзем дә адашкан бер
Авыл баласы.
Язмыш җиле адаштырды
 Япь-яшь чагымда.
Йөрәгемнең һәр тибеше
Өйне сагына.

## Көзге бишек җыры

Ак биләү-томанга төреп,
Тирбәтә көзге иртә:
«Әлли-бәлли бәү итә,
Йокла, сеңел, тыныч күңел,
Кышларга әле иртә,
Кышларга әле иртә...»

Чәчләремнән сөеп-сөеп,
Җилләре кубыз чиертә:
«Әлли-бәлли бәү итә,
Йокла, сеңел, тыныч күңел,
Кышларга әле иртә,
Кышларга әле иртә...»

Болытларга тиеп-тиеп,
Торналар иңри күктә:
«Әлли-бәлли бәү итә,
Йокла, сеңел, тыныч күңел,
Кышларга әле иртә,
Кышларга әле иртә...»

Кышларга әле иртә дә,
Нигә соң кошлар китә?
Нигә көзнең йөзе моңсу,
Нигә җил яшен сөртә?
Әлли-бәлли бәү итә,
Төш кебек гомер үтә...

## Кайталмадым

Авылымда сабан туе бүген,

Гөр киләдер Шушма буйлары.
Тыя алмыйм чабыш аты булып
Туган якка очкан уйларны.

Апаларның сулы чиләгедәй
Мөлдерәмә тулы күңелем,
Мәйданнарга кайтып, яшь үләнгә
Көмеш тамчы булып түгелдең...

Ярсып тибә күкрәгемдә йөрәк,
Батыр беләгенә көч биреп.
Әниемнән калган ак сөлгене
Сыйпап куя кулым бер сөеп.

Күзем төшә яшел гармуныма,
Үксеп елар төсле, кагылсам...
Читлектәге коштай өзгәләнеп
Моңланасың икән, сагынсаң.

Авылымда сабан туе бүген,
Гөр киләдер Шушма буйлары.
Кайталмадым. Кичерегез мине,
Сабантуйсыз үткән елларым...

## Яшьлек дустыма

Читләп узган сине ачы җилләр,
Кагылмаган көләч йөзләреңә.
Элеккечә бер сокланыйм әле
Пар йолдыздай нурлы күзләреңә!

Читләп узган сине кыраулар да,
Көмешләнгән бераз чигәң генә.
Элеккечә толымнарың уйный
Дулкын булып нәфис иңнәреңдә.

Читләп узган сине кар-бураннар,
Кагылмаган хисле йөрәгеңә.
Элеккечә, җанны җылытырлык
Кайнарлык бар әйткән сүзләреңдә.

Читләп узган сине вакыт үзе,
Кагылмаган гүзәл йөзләреңә.
Син калгансың җәйләр кочагында,
Ә мин инде кердем көзләремә,
Язмыш җиле үтте үзәгемә...

## Яшьлек

Яшьлекнең күкләре биек,
Болытлары бөдрә, ак.
Әй яшьлек...
Ак болытка башны салып,
Бер ваемсыз агар чак!

Яшьлекнең толымы озын,
Күлмәгендә юк бер тап.

Әй яшьлек...
Гөнаһлы фани дөньяда
Фәрештәдәй калыр чак!

Яшьлекнең күзләре нурлы,
Ә йөзләре һәрчак шат.
Әй яшьлек...
Сагышларны көлә-көлә
Агымсуга салыр чак!

Яшьлекнең юлдашы — хыял,
Күңеле — канатлы ат.
Әй яшьлек...
Аяк очларына басып,
Күктән йолдыз чүпләр чак!

Яшьлекнең кышлары — мизгел,
Язларыдыр — мәңгелек.
Әй яшьлек...
Яз булып гомер кышыма
Бер керсәң иде килеп,
Яшьлек — яз ул мәңгелек!

# Күңел күзе җитмәс ераклык юк...

*** * ***

Кыш әллә елап китәме,
Язлармы килә җырлап?
Бәллүр тамчылар тавышы
Колакта тора чыңлап...

Яшьлегем җырлап китәме,
Картлыкмы килә елап?
Гомернең моңлы агышы
Колакта тора чыңлап...

## Гомер йомгагым

Уйнап туеп, кочып йоклап киткән
Йон йомгагын мәче баласы.
Чуалыплар беткән җепләренең
Очын хәзер ничек табасы?

Уятырга жәлләп назлыкайны,
Кузгатырга кыймый күңелне
Карап торам. Гомерем — ак йомгагым
Бик кечкенә калган түгелме?

Мәче баласыдай уйный-уйный
Сүтелгән шул сизми, үтелгән.
...Офыкларның алсу аръягыннан
Ак болытлар гына күтелгән.

Киләчәкнең серле төннәреннән
Әллә ниләр өмет ителгән!

Айның чите һәр кителгән саен,
Күңелнең дә чите кителгән.
Мәче баласыдай уйный-уйный
Сүтелгән лә гомер, үтелгән...
Йә Ходаем, сакла мине берүк
Яшәп туеп җирдән китүдән.

## Гомер сорыйм

Уянам да төшләр юрыйм:
Яманнарын суга сөйлим,
Яхшыларын кызым тыңлый.
Ә соңыннан
Барыбызга гомер сорыйм,
Аллаһыдан гомер сорыйм.

Уянам да уйлар уйлыйм:
Яманнарын әйтеп тормыйм,
Яхшыларын ирем тыңлый.
Ә соңыннан
Барыбызга гомер сорыйм,
Аллаһыдан гомер сорыйм.

Уянам да җырлар җырлыйм:
Яманнары булмый җырның,
Яхшыларын дуслар тыңлый.
Ә соңыннан
Барыбызга гомер сорыйм,
Аллаһыдан гомер сорыйм...

*** * ***

Тау белән тау да очраша,
Җирләр тетрәсә әгәр.
Җаным тетри. Синең җанга
Киләме берәр хәбәр?

Йөрәгемдә вулкан ата,
Шаһиты — көлсу болыт
Явамы сезнең якларда
Утлы хатирә булып?

Кайнар чишмә — ике күзем,
Эзеннән көя йөзем.
Тау белән тау да очраша,
Без таулардан да түзем.

## Тузганак

Сары-сары тузганак,
Кал әле алтын килеш!
Язның яшел күкрәгендә
Кабынган ялкын килеш.

Әй, матур ла чәчләрең!
Ябынма мамык шәлең.
Алда җәй бит, кыш түгел,
Син дә... очар кош түгел.

Кош түгел без, кош түгел.
Шәл мамыгы очканга да
Алдана тиле күңел...

* * *

Таулар биек, текә, диеп,
Торабыз карап кына.
Кемдер менә, безгә менә
Үзән дә ярап тора,
Торыйк ла карап кына.

Диңгез шаулый, ирек даулый,
Дулкында кораб тора.
Кемдер йөзә, безгә исә
Ярлар да ярап тора,
Торыйк ла карап кына.

Кем — биектә, кем — иректә,
Гомерләр ага тора.
Кем яшәгән, ә без икән
Торганбыз карап кына,
Булдык ла харап тора...

* * *

Ярый әле җилләре бар
Уйларны җилгәрергә.
Усалларын, ямьсезләрен
Очыртып җибәрергә.

Яңгырлар бар, юа торган
Тапларын күңелләрнең.
Сөлгенең дә эленгәне —
Җиледән чигелгәне.

Кояш бар тагын йөрәкнең
Бозларын эретүче...
Җил, Яңгыр, Кояш баласы —
Бәхетле син, и Кеше!

* * *

Эңгер-меңгер... Көн бер, төн бер.
Төн бер, көн бер.
Иң җайлы чак, уңайлы чак,
Янар өчен кулай бу чак:
Кояш баткан, ай калыкмаган,
Кабын да кит җан-чакмадан.
Йә бул кояш, йә ай бул син,
Балкуыңны дөнья күрсен,
Бәя бирсен.
Эңгер-меңгер... Көн бер, төн бер.
Син — бер, мин — бер һәм бер — гомер,

Яшәп өлгер, яшьнәп өлгер!

## Сер сандыгым

Күңелемнең аулак почмагында
Сер сандыгым ята ябылып.
Белмәсен дә беркем, сизмәсен дә,
Кузгатмасын саксыз кагылып.

Гомерем буе җыйган байлыгым шул:
Рухи дөньям — хәләл табышым.
Хыялымның иң татлысы анда,
Иң әчесе анда сагышның.

Хисләремнең иң-иң кайнарлары,
Сүзләрнең бар боздай салкыны.
Кара күмерләре көюләрнең,
Януларның уты, ялкыны.

Хыянәтнең, авыр болыт сыман,
Тормыш күген каплый торганы.
Мәхәббәтнең, изге фәрештәдәй,
Бар афәттән саклый торганы.

Күңелемнең аулак почмагында
Сер сандыгым ята ябылып.
Бүген ачып бер җыр очырдым мин,
Рәнҗетмәгез саксыз кагылып!

## Үз-үземә теләк

Усалланма, телем, усалланма,
Ямьсез сүзләр әйтмә дошманга да.
Төчеләнмә, ләкин татлы бул син,
Гадилегең белән затлы бул син.

Усалланма, йөзем, усалланма,
Ачык бул син хәтта дошманга да.
Якты бул син, балкы кояш кебек,
Кем шатланмас җирдә кояш күреп.

Усалланма, кулым, усалланма,
Таш атма син берүк дошманга да.
Юмарт бул син, таң җиледәй йомшак,
Учларыңда янсын сүнмәс учак.

Усалланма, күңелем, усалланма,
Ачу саклама син дошманга да.
Изгелектә булсын уең-гамең,
Тоярсың тик шулчак яшәү ямен.

Үз-үземә теләк теләдем,
Һәммәгезгә булсын теләгем!

* * *

Һәркем белгән, аңлаганны,
Укыганны, ятлаганны,
Һәр көн күргән, ишеткәнне,
Инде күрми дә үткәнне
Сүзгә төреп җыр-сер итү —
Азмы, күпме бер шагыйрьгә?

Ел-гасырлар аша үтеп,
Сүзен сүзгә аннан сүтеп,
Серне ачу бар дөньяга,
Таң калдырып өр-яңадан —
Азмы, күпме бер шагыйрьгә,
Бер йөрәккә, бер бәгырьгә?

* * *

Күңел күзе җитмәс ераклык юк,
Биеклек юк, хыял менмәгән.
Тирәнлекнең төпләрендә — сагыш,
Йөрәк юктыр моны белмәгән.

Сабырлыклар — алтын, сүзләр — көмеш,
Күзләр, дөрес, алмаз бәясе.
Яши-яши аңлый икән кеше
Һәрнәрсәнең үлчәм-мәгънәсен.

Мәңгелеккә югалтуны менә
Бизмәннәргә салган бер мәлем.
Бушлыкның да җанны сытып сыгар
Авырлыгы барын белмәдем...

## Хыял белән хушлашу

Иннек сөрттем, аннан үптем дәфтәр битен,
Ал күбәләк пәйда булды ак кәгазьдә.
Шундый сак һәм назлы иде сулыш-тыным,
Җан иңдерми күбәләккә калдым әздән.

Әздән генә калган кебек яшьлегемдә
Җан иңдерми күбәләктәй ал хыялга...
...Иннек сөрттем, янә үптем дәфтәр битен,
Яшь тамчысы тәгәрәде ал буяуга.

## Үтә гомер

Язлар көтеп үтә гомер,
Җәйләр җиткәнен көтеп,
Көтмичә дә килгән кышның
Үтеп киткәнен көтеп.

Назлар көтеп үтә гомер,
Бәхет үпкәнен көтеп,

Көтмичә килгән кайгының
Үтеп киткәнен көтеп.

Үтә гомер, яшәп үтә:
Елмаеп, елап, көлеп,
Көтмичә килгән үлемнең
Үтеп китмәсен белеп...

## Тамаша

Башларга вакыт, димәле,
Тормышны тәмамларга.
Кабатланмас тамаша бит,
Тырыш гел дәвамларга.

Үзең уйна, үзең җырла,
Алкышларга үзең күм.
Тәнәфестә онытыл да
Кыңгыравын үзең бир.

Бер, ике, өч... тик уяу бул!
Өченчесе — соңгысы.
Йөрәк белән ишетәсен
Күңел белән тыңлыйсы...

Сәхнәдә — бәхет балкышы,
Тәннәр-җаннар камаша!
Мәңге уйнап туймый торган
Тормыш — гүзәл тамаша,
Тормыш — классик тамаша.

## Картлык

Картлык килә. Ах, хәйләкәр төлке!
Эз бутаган була, әйләнә.
Сизмәгәндә күңел биген ачып,
Көзне кертмәк була җәйләргә.

Гомереңнең калган өлешенә
Мин хуҗа дип, картлык, алданма.
Аяк очларында, кача-поса,
Хуҗа йөрми — шуны аңла ла.
Йөрәгемә күптән язлар хуҗа,
Җәй төсләре балкый күзләрдә.
Чәчләрдәге көмеш пәрәвез дә
Ятьмә бит ул килер көзләргә.

Йә инде, йә, үпкәләмә, бәлки,
Бер ачармын сиңа ишекне.
Җырлый-җырлый икәү тирбәтербез
Оныкчыгым яткан бишекне.

## Тормыш арифметикасы

Кояшлы көннәр санына
Куштым кояшсызларын.
Шуннан белдем гомерләрнең
Сизелми дә узганын.

Кояшлы көннәр саныннан
Кояшсызларын алдым.
Түм-түгәрәк бер сан булып
Бәхетем торып калды.

Тапкырлыйммы, бүлимме —
Ни көткәнен белимме?
Тапкырласам, күп була,
Бүлсәм, өмет юк була...

* * *

Туйлар узды, туннар тузды дигән
Уйлар килгән саен башыма,
Иске тунын әйләндереп киеп,
Дөнья чыга көлеп каршыма.

Шундый кызык, рәхәт булып китә,
Биеп китә күңел, очынып!
Ирексездән ныграк кыса йөрәк
Куык таккан
Гомер җепләренең очыннан...

* * *

Кеше күрмәгәндә биеп,
Ишетмәгәндә җырлап
Яшәү, беләм, кызганыч...

Кеше күрмәгәндә елап,
Ишетмәгәндә үксеп
Яши белү куаныч...
Шул күңелгә юаныч.

* * *

Талларга кунып сайрый кош,
Ташларга басып сайрый.
Сайрар урын сайлап тормый —
Тимер читлек тә ярый.

Йөрәктә моң булган чакта,
Күңелләр тулган чакта,
Коштан үрнәк ал икән —
Бер өздереп кал икән!
Кунып кайгы кашларына,
Басып сагыш башларына,
Очып вакыт өсләреннән,
Кочып якты хисләреңне,
Җырла икән онытылып,
Дөньяны кызыктырып.

Ә дөньямы? Ә дөнья
Аучы песи борыныдай

Буялган канга, йонга.
Җаннар сагалап тора,
Тотып алгалап тора...

*** * ***

Ачулы чагыңны уйласам,
Уем елый.
Шаян чагыңны уйласам,
Уем көлә.
Битараф чагыңны уйласам,
Уем үлә...

*** * ***

Кайгыларга төренгән бар,
Шатлыкларга — күмелгән.
Кайсы күбрәк булганлыгын
Кем санаган, кем бүлгән?

Алай дисәм, чәчләремнең
Аклары күп карадан.
Газиз башкайларым, димәк,
Барысын бүлгән, санаган...

## Танымыйм

Танымыйм бүген үземне,
Башкалар, белмим, ничек.
Йөри бит усал бер очкын
Күздән йөземә күчеп тә
Йөздән күземә күчеп.

Очкыннан ялкын кабынып,
Нишләрмен йөрәк янса?
Янып, каралып, таралып,
Кара күмергә калса?

Кара йөрәк нигә кирәк,
Усаллык, мәкер тулы?
Кем соң җырлар минем өчен
Яхшылык дигән җырны да
Матурлык дигән җырны?

Танымый үзең-үзеңне
Яшәве авыр ничек.
Сүндерәм усал очкынны,
Өлгергәнче
Күздән йөрәккә күчеп тә
Йөздән йөрәккә күчеп.

## Энә һәм Җеп

Баскан җирем аллар-гөлләр итәм,
Күпләр сокланырлык тырыш мин.
Ничә гасыр утка-суга кереп,

Чыныгулар алган корыч мин,

Диеп, Энә әй мактанды беркөн,
Ялтыр-йолтыр килде күзләре.
Шуңадыр ла нурдай ефәк Җепнең
Өзелгәнен хәтта сизмәде.

Әйтте-чәнечте, чәнечте-әйтте тиз-тиз,
Дан җырлады сүзе үзенә.
Ак җирлектә ярылып калды шулчак:
Гөл дә түгел, матур җөй дә түгел,
Кирәкмәс бер тишек-эз генә...

* * *

Идән җәймәседәй,
Яңа яуган ап-ак карга күмеп,
Өсләрендә тыпыр-тыпыр биеп,
Урамдагы чит коймага элеп,
Тәнне-җанны, их, кагасы иде!

Очыртып бар пычрак-тузаннарын,
Онытып мең таптап узганнарын,
Күрсәтеп гел тишек-тузганнарын,
Җиңеләеп, их, каласы иде!

Юк, булмый шул үз-үзеңне җиңеп,
Ни уйламас кеше, әйтмәс көлеп,
Карда калган соры эзне күреп.

* * *

Бер карага, бер сарыга буйыйм,
Бер җирәнгә манам чәчемне...
Мин генәме, хәер, үз төсләрен
Заман буявына яшергән.

Йөзләремә тонык кершән сөртәм,
Күзләр тоныклана үзләре.
Мин генәме, әйе, мин генәме
Дөньяларга ярап үзгәрдем...

Көзгеләрдән инде көзем карый,
Елмая ул серле, «ник?» дисәм,
Янәшәмә кызым килеп баскан,
Яшьлегемдәй ихлас, көлемсәр...

## Күңел

Җәйләрнең кыл уртасында, күрче,
Кылт итә дә кышлар искә төшә...
Нишләтәсең инде бу күңелне,
Үз канатын үзе, юләр, кисә.

Бәргәләнә аннан, өзгәләнә,
Оча алмыйм, аһ, мин мескен, диеп.
И әйтәсе килә: газаплан ла,

Үз канатың үзең кистең, диеп.

Тик тыелам. Күңел күбәләгем
Шундый хисле бит ул, шундый нечкә!
Беләм аның кышын очачагын,
Кылт итеп бер җәйләр искә төшсә.

*** * ***

Җил иркәли сөеп чәчләремнән,
Кояш үбә шундук керфектән.
Сихри халәт — бүген мин җиһанның
Тын алуын хәтта ишетәм.

Тыны белән тартып алмасмы дип
Шикләнеп тә куям, и юләр!
Чындыр ул «яз әсир итә аңны
Һәм исертә җанны» диюләр...

Тыя алмыйм ак дөньяны кочып
Вальс бию дигән теләкне,
Назлар җыеп бер әйләнсен очып,
Җил учына салам йөрәкне.

*** * ***

Ак юл булып бәхет сузылды да
Көтмәгәндә генә өзелде.
Ак бәхетнең соңгы ак тузаны
Кочып елый бугай теземне.

Юк, кар икән. Салкын. Хәер, барыбер,
Җан туңармы башта, әллә тән.
Җырга күчкән соңгы сулышым бу —
Синсез яшәү җирдә юк бүтән...

## Ташлама мине, мәхәббәт!

Ташлама мине, мәхәббәт,
Үтенәм синнән, зинһар,
Караңгы төннән коткар син,
Томанлы көннән коткар.

Ташлама мине, мәхәббәт,
Канат куй күңелемә.
Бераз гына очыйм әле
Ак дөнья киңлегендә.

Ташлама мине, мәхәббәт,
Ялкын сал йөрәгемә.
Тагын бер яз сайрар идем
Кунып моң тирәгенә.

Ташлама мине, мәхәббәт,
Үтенәм синнән, зинһар,
Бар дөньяга нәфрәтләнеп
Ялгыз үлүдән коткар...

Ташлама мине, мәхәббәт!

*** * ***

Түздем,
Юкка-барга яшем түгелмәде.
Түздем,
Уңга-сулга серем сибелмәде.
Түздем,
Җил-давылдан талдай бөгелмәдем.
Түздем,
Моң-сагыштан кылдай өзелмәдем.
Түздем,
Чөнки ялгыз идем үзем...

Бүген син янәшә.
Булды әллә нәрсә —
Юкка-барга елыйм,
Серем сөйләп туймыйм,
Бөгеләмен талдай,
Өзеләмен кылдай,
Мин бәхетле бугай!
Ничек түзим?

*** * ***

Тоткынлыкта иде хисләр —
Күңел читлеге ябык.
Ачкычлар җуелган иде,
Булмаслык итеп табып.

Бикләнгән иде йөрәк тә,
Күзләрдә иде пәрдә.
Синсез дөньяга чыкмыйм, дип,
Бирелгән иде вәгъдә...

Асты өстә бүген өйнең,
Актарам почмакларын.
Уңга сибәм, сулга сибәм
Көлләрен ул чакларның.

Башым тотып уйга талам,
Карап алам көзгегә.
Акылымны җуяр булып
Ачкыч эзлим,
Чыгар өчен үземнән...

## Беренче мәхәббәт

Күбәләк кар — минем җаным,
Бөтереләм буранда.
Учларыңда эрер идем,
Чыкмыйсың шул урамга.

Өең синең якты, җылы,
Бай ул — тиң дәрәҗәңә.
Бәргәләнә туңган күңелем

Боз каткан тәрәзәңә.

Тиздән, беләм, язлар җитәр,
Эреп агар ул бозлар.
Кардай саф кызны сагынып,
Синең дә җаның сызлар...

*** * ***

И салмак ла адымнарым...
Уңнан-сулдан, сулдан-уңнан
Узалар да китәләр.
Югыйсә мине дә анда,
Югыйсә мине дә алда
Көтми түгел, көтәләр.

«Узганнарны куып бару
Һәм дә көтү бердәй авыр»
Диюләре хак инде.
Булсак та без бу дөньяда
Бердәй түзем, бердәй сабыр,
Тик... бәхеткә ят инде.

*** * ***

Челпәрәмә килде бәллүр дөнья,
Аяк асты — ватык пыяла.
Балачагы хыяллары белән
Яланаяк калды кыз бала.

Өзгәләнеп дәште яшь йөрәге:
«Кулларына мине кем ала?»
Сөю килде, бәхет кочагында
Йолдызларга ашты кыз бала.

Сөю, бәхет, гел шатлыктан торган
Ул мизгелләр ник тиз уза ла?
Хәлсезләнеп, сагыш канатында
Кабат җиргә төште кыз бала.

Челпәрәмә килгән шул ук дөнья,
Аяк асты — ватык пыяла...

*** * ***

Кар базыдыр синең акыл —
Җәен-кышын салкын.
Сатасың гел миңа аны,
Мең арттырып хакын.

Күңел белән түлим инде,
Түлим йөрәк белән.
Сатар өчен алучы да
Кирәктер ул, беләм.

Салкын акыл, кайнар йөрәк —

Эреп ага гомер...
Нигә соң без икебез дә
Кайнар җаннар түгел?
Кояш була алмасак та,
Янар идек дөрләп.
Тормышыбыз көлләрендә
Шытар иде гөлләр.

Нигә син артык акыллы,
Ник мин артык җүләр?

## Кар кызы ялваруы

Син табылсаң, мин югалам,
Барыбер табыл, табыл!
Беренче һәм соңгы тапкыр
Чәч бөртегемә кагыл.

Беренче һәм соңгы тапкыр
Иреннәремә сарыл.
Йөрәкне кайнар тамчы ит,
Гәүдәмне — апрель кары.

Сөеп үлү — бәхет, ләззәт.
Эреп үлү, ай, авыр...
Син табылсаң, мин югалам,
Барыбер табыл, табыл!

*** * ***

«Сөю» дигән чолганышта калсам,
Ак күңелем әләм итәр идем,
Җилфердәтеп ап-ак әләмемне,
Йөгерә-атлый каршы китәр идем.

«Сөю» дигән чолганышта калсам,
Эһ тә итми әсир төшәр идем,
Хисләремне, йөрәк серләремне
Бәйнә-бәйнә сөйләп чишәр идем.

«Сөю» дигән чолганышта калсам,
Качу юлын үзем бикләр идем.
Ирегемне, газиз гомеремне
Татлы газап белән чикләр идем,
«Сөю» дигән чолганышта калсам...

*** * ***

Алма коя итәгемә август көне,
Йолдыз коя чәчләремә август төне.
Алма исе килеп торган йолдыз булып
Яшим микән хәтереңдә әл дә синең?
Яшим микән?
Дәшим микән еллар аша сискәндереп,

Уятыйммы җан-тәнеңне хисләндереп?
Кайтарыйммы үткәннәргә тезләндереп,
Елатыйммы «бәхил...» дигән сүзгә төреп?
Нишлим икән?
Сүзсез генә, синсез генә
Күзләремә китәм кереп...

## Гашыйк булыйк

Гашыйк чагын онытканнар,
Оныткан тансык чагын,
Әйдәгез, быелгы язга
Бер гашыйк булыйк тагын!

Яныпкөеп йөрик күзләп
Ак каеннарны читтән.
Алланыйк алсу алмадай,
Җилләр үпсә дә биттән.

Гөрләвекләр гөрләвеннән
Әй көлик кызык табып!
Кояшка ачыйк күңелне —
Тамчыдай торсын тамып.

Яшьлек кайткандай сөенеп
Көтик кошлар кайтуын.
Кар суы да басмас итик
Йөрәкләрнең ярсуын.

Сөюдән балкыган җанны
Яз ничек күрми узар?
Гашыйгым, дип, тансыгым, дип,
Умырзаялар сузар...

## Тану

Пәлтә якаңны күтәреп
Яшермәче йөзеңне.
Таныдым бит, таныдым ич,
Таныдым ла үзеңне.

Башың иеп җиргә кадәр,
Кызулатма адымың.
Күреп торам, сизеп торам:
Син дә мине таныдың.

Яшьлек хатам булган икән
Бирү сиңа җанымны...
Бүген алам. Нинди бәхет —
Җан үз тәнен таныды!

## * * *

Ак томанга төренеп атты
Җәйнең соңгы таңы...
Йөрәгеңдә, әйтче, бүген
Миңа урын бармы?

Алма булып өзелеп төште
Җәйнең соңгы көне...
Янында — мин, ә күңелең
Уйлый икән кемне?

Йолдыз булып әй атылды
Соңгы төне җәйнең...
Алсу җиләк иренеңдә
Тойдым миләш тәмен,
Әче күзләр тәмен...

## Буранда

Ак кышларның гүя аккошлары —
Ак каеннар йөзә урамда.
Чуклы-чуклы канат очларына
Кар мамыгы зырлап урала.

Әйлән-бәйлән уйный тартма-йортлар,
Уйларымның уртасына басып.
Тәрәзләрдә җемелдәшкән утлар
Бүген миңа йолдызлардай тансык.

Көртләр ярып барам синең арттан,
Эзләреңне күмә көнчел буран.
Ни була соң, борылып кулың бирсәң,
Адаштырмам диеп, адаштырмам...

## * * *

Ничә сүтеп, чәчләремне
Үрмәдең.
Ничә үксеп, яшьләремне
Күрмәдең.
Ничә китеп, үз-үзеңне
Алдадың.
Ничә килеп, гомерлеккә
Калмадың.
Ничә белеп, бүген генә
Аңладым:
Сихерләнгән алтын бөҗра —
Балдагың.

## * * *

Тән ярасын төзәтүче
Үсә мең төрле үлән.
Табиб бирә киңәшләрен,
Туганнар, күрше-күлән.

Җан ярасын төзәтүче
Үләнне каян алыйм?
Беркем күрми, беркем белми
Җанымның яраларын...

* * *

Көтәбез шул, гомер буе учта йөртер сөйгән яр дип,
Көтәбез шул, гомер буе саклап торыр бәхет бар дип,
Без — хатын-кыз.
*Фирүзә Җамалетдинова*

Әйткәннәре өчен үкенәбез,
Әйтмәгәне өчен тагын да.
Елар чакта бик еш без көләбез
Һәм елыйбыз көләр чагында.

Ялварып та кемдер ала алмый
Тик бер караш бездән наз тулы.
Ә бирәүнең, сорамаган килеш,
Булабыз без җан һәм тән колы.

«Болан» диләр безне, «елан» диләр,
«Роза гөл» йә «шайтан таягы».
Сөю, нәфрәт... Үлчәүләргә салсаң,
Басар микән, белмим, кай ягы?

Чишә алмас беркем серебезне,
Очларына чыкмас уйларның.
Без — хатын-кыз! Сигезенче түгел,
Тәүге могҗизасы дөньяның.

## Яз башы

Бөтерелеп карлар куна
Бүрексез башларыңа.
«Яз башыннан яланбаш тик
Хыялый башлар гына!» —

Дип көләсең яңгыратып
Салкын шыксыз урамны.
Шул көлүең тып-тын итә
Күңелдәге буранны.

Сак кагылам чәчләреңә,
Учымда эри кары.
Яз башы бу, язның башы —
Гомер уртасы бары.

* * *

Әрсез тамчы түгел шул мин,
Түбәдән тама торган.
Чишмә түгел, таш астыннан
Үз юлын таба торган.

Җил дә түгел, киртәләрне
Актарып сала торган.
Гөл дә түгел, иркәләүне
Назланып ала торган.

Алай дисәм,
Уем — тамчы, моңым — чишмә,
Нәфрәтем — җил, сөюем — гөл
Түгелмени?!

Мең халәте күңелемнең
Табигатьнең үземени...

* * *

Башланды көзге явымнар,
Яфрак катыш яңгырлар,
Сагыш булып сарылулар,
Моң-зар булып тамулар.

Башланды көзге янулар,
Учактан көл калулар,
Тәлгәш-тәлгәш миләшләрдән
Йөрәккә ут алулар.

Башланды көзге алдану,
Сарыны алтын диеп,
Назлану, узса да йөзгә
Пәрәвез җебе тиеп.

Башланды көзге ялгану
Кышларның итәгенә,
Һәм соклану ак дөньяга,
Тугандай кичә генә.

Башланды көзләр, башланды...

* * *

Нарат урманында көзләр яшел,
Бөтенләйгә шунда кереп яшим
Дигән идем, искә төште җәйләр,
Дәвалаучы йөрәк ярамны.
Нарат урманында көзләр яшел,
Җәйләр генә...
Җәйләр генә салкын, караңгы...

Уҗым кырларында көзләр яшел,
Бөтенләйгә шунда калып яшим
Дигән идем, искә төште җәйләр,
Тургай җыры иткән аһ-зарны.
Уҗым кырларында көзләр яшел,
Җәйләр генә...
Җәйләр генә иртә, аһ, сары...

Яшьлек урамында көзләр яшел,
Бөтенләйгә шунда кайтып яшим
Дигән идем, искә төште юллар,
Бормалы да артык, тузанлы.
Яшьлек урамында көзләр яшел,
Юллар гына...
Кабатлыйсым килми узганны...

* * *

Туфлиемә ияреп кергән
Сары яфрак.
Әйтерсең лә алтын тәңкә
Ята ялтырап.

Күр әле син әрсезлеген,
Батырлыгын!
Бүлмә гөле көнләшерлек
Матурлыгын!

Хәйләкәр көз белә минем
Шагыйрьлекне.
Һәр яфрагын калдырмакчы
Шигырь итеп.

## Табигать, өйрәт яшәргә...

Кояшка үрелә гөлләр,
Күңел тартыла гөлгә.
И гөлем, өйрәт яшәргә
Сөенеп якты көнгә.

Ай йөзә күкне балкытып,
Йолдыз күз кыса кемгә?
Йолдызым, өйрәт яшәргә
Сокланып серле төнгә.

Каеннар шаулый урманда
Кошлар чыгарган көйгә.
Кошчыгым, өйрәт җырларга
Өздереп туган телдә.

Ак колын чаба җәйләүдә,
Ялы җилферди җилдә.
Әй, җилем, өйрәт яшәргә
Баш ими Ватан-илдә!

«Гомерләр узды», — димәм мин,
Син дә:«Соң инде...» — димә.
Табигать, өйрәт balaңны
Яшәргә газиз җирдә.

## Үкенеч

Балачакта
әнисенең яңа ефәк шәлен
курчагына күлмәк итеп тураклаган
бер мин генә түгел.
Үсеп җиткәч
әнисенә яңа ефәк шәлләр
апкайтырга өлгералмый калган
бер мин генә кебек...

* * *

«Нинди төз буй! Нинди мәһабәт сын!
Горурлыкка һәйкәлдер бу нарат.
Эх, яшисе иде дөньяларда
Наратларча — өстән аска карап!

Җилле бөдрә башны-ябалдашны
Бер кояшка, тик кояшка иеп,
Эх, яшисе иде наратларча
Болытларга тиеп, тиеп, тиеп!» —

Диеп уйларга да өлгермәдем
Күкрәп үскән нарат урманында
Зәгыйфь куак бүлде юлларымны:
«Наратларча яшәп мәхрүм итмә
Бездәйләрне кояш нурларыннан,
Бездәйләрне кояш нурларыннан...»

## Миләш җыям

Миләш җыям тәлгәш-тәлгәш өзеп,
Иплән кенә салам чиләккә.
Юмарт көзнең утлы бу җимеше
Шифа булыр, бәлки, йөрәккә.

Миләш җыям. Тынып калган урман,
Каеннарга сарган сары моң.
Басар өчен йөрәк әрнүләрен,
Иң әчесен җыям даруның.

Үткән гомерем тоташ җәйләр иде,
Татлы җиләк иде өзгәнем.
Инде хәзер татыр вакыт җитте
Миләшләрен әче көзләрнең...

## Беренче буран

Буранның да була икән
Көтеп ала торганы.
Хуш киләсең, яңа кышның
Иң беренче бураны!

Бар дөньяны сафландырдың,
Шатлык китердең безгә.
Күр әле, ничек килешә
Ап-ак төс йөзебезгә!

Ә күзләрдә моңсу кышның
Бүген эзе калмады.
...Ноябрьнең ак бураны
Көзне кышка ялгады.

## Карлар ява

Карлар ява, яңа карлар ява...
Табигатьнең юмарт бүләге

Мамык шәлдәй иңнәремә ята
Һәм иркәләп үбә күзләрне.

Ирексездән кулларымны сузам:
Күбәләк-кар, кун син, ятсынма!
Беләсең бит сагынып көткәнемне,
Җылы учларымны тарсынма.

Рәхәт салкынлыгың тойсын тәнем,
Ә җаныма күчсен сафлыгың.
Күңелдәге бар тапларны юсын
Яктылыгың, садә аклыгың.

Юлларыма җәел ак җәймәдәй,
Тәрәзәмә бул син ак пәрдә.
Язларыма кадәр озата бар,
Бүгенгедәй ак һәм пакь хәлдә.

Карлар ява, яңа карлар ява,
Табигатьнең юмарт бүләге...
Ак бәхетләр вәгъдә иткән кышка
Ышан әле, ышан, йөрәгем!

## Кышкы рәшә

Тәрәз каршымда ак каен
Челтәр шәлен ябынган,
Ә шәленең чукларына
Энҗе-мәрҗән тагылган.
Җемелди алар кояшта
Төрле төсләргә кереп.
Мин түгел, каен үзе дә
Шаккаткан шәлен күреп.

Кымшанмый да басып тора
Оялчан кәләш сыман.
Нindидер могҗиза көтеп
Тын калган кышкы урам.

Нindидер могҗиза көтеп
Кысылып куйды йөрәк.
Түзмәдем, чыгып йөгердем
Каен янына тизрәк.

Ашыгып, эх, ашыгып шул
Кагылдым чукларына.
Энҗе түгел, гап-гади кар
Коелды учларыма...

* * *

Болытлар куера күкләрдә —
Бик таныш күренеш күпләргә.
Нишләргә?
Кала тик, муенны җыерып,
Карлы боз, яңгырлар көтәргә...

Болытлар куера күкләрдә —
Бу халәт бик таныш күпләргә.
Нишләргә?
Кала тик, йомарлап йөрәкне,
Борчылу, күз яше көтәргә...

Болытлар куера күкләрдә —
Нишләргә, нишләргә, нишләргә?
Көтәргә, көтәргә, көтәргә.
Яңгырлы күз яшен иртәгә
Салават күпере итәргә
Кояш бар!
Әнә ул, елмаеп,
Болытлы керфеген күтәрә.

*** * ***

Ак чәчәкләр ява...

*Һ.Такташ*

Карны чәчәккә тиңлибез,
Чәчәкне карга — һич юк!
Кемнең башына килсен соң
Язын юксыну кышны?

Карны мамыкка тиңлибез,
Мамыкны карга — көлке...
Шәл мамыгы шундый җылы —
Җанны җылыта төсле!

Карны тәңкәгә тиңлибез,
Тәңкәне — карга... Тукта!
Икесе бердәй эри ич,
Килеп керүгә учка.

Тәңкә карлар, кар-тәңкәләр
Явалар эрер өчен,
Ак чәчәкләр матурлыгын,
Ак мамыклар җылылыгын
Бәяли белер өчен.

# Каен белән серләшү

Әй, каенкай, сизәсеңме,
Яз килә бит дөньяга!
Бу синең ничәнче язың?
Минекеме? Сорама!
Әйтмим, әйтмим,
Син дә әйтмә,
Елларны без санамыйк,
Язларда гына булса да
Мәңге яшь булып калыйк.
Сине кояш уятамы
Иркәләп, назлап, үбеп?
Минем дә ярым янымда
Балкый нәкъ кояш кебек!
Яңа күлмәгең әзерме,

Җәй башында киясе?
Минекенең калды бары
Итәкләрен бөгәсе...
Каенкаем, сизәсеңме,
Яз килә бит дөньяга!
Бу синең ничәнче язың?
Минекеме? Сора...ма...
Аһ, ни соң бу?
Җилләре дә
Телләрне бәйләндерә.
Яңа яз килә дөньяга —
Башларны әйләндерә.

## Күкрәү

Язгы күкрәү җирне уятыр да,
Җәйгеләре күкне уйнатыр.
Җир белән күк яшен угы аша
Сөю офыгында очрашыр.

Бу мизгелнең шаһитлары — күзләр —
Сукыраймас өчен йомылыр.
Колакларны ярып дөнья иңрәр —
Бәхет җыры әнә шул булыр.

Күкрәү арты күкрәү өмет итеп,
Тын да алмый көтәр бар җиһан.
Саф тамчылар сискәндерер тәнне,
Күккә ашар юлын барлар җан...

* * *

Тын бакчада сихри иртә,
Күбәләк саф чык эчә.
Әнә шулай галәм сере
Бу нәни җанга күчә.

Серне чишеп өлгерер ул
Бары тик алсу гөлгә...
Йә күбәләк, йә гөл булып
Туасы мәллә җиргә?
Белер өчен Галәм серен...

## Яз алдыннан

Яз алдыннан шундый көннәр була —
Кар астында чишмә җырлап тора.
Колакларда моңы чыңлап тора,
Яз алдыннан шундый көннәр була!

Яз алдыннан шундый көннәр була —
Чишмә түгел, ярсу диңгез тына.
Суыклардан шартлап агач сына,
Яз алдыннан шундый көннәр була...

Яз алдыннан шундый көннәр була —
Сөю белән саф йөрәкләр тула.
Керфекләргә бәхет нуры куна,
Яз алдыннан шундый көннәр була!

Яз алдыннан шундый көннәр була —
Кышын чәчәк аткан гөлләр сула.
Җылы кояшта да җаннар туңа,
Яз алдыннан шундый көннәр була...

*** * ***

Ун тәңкәгә ике чәркә
Көнбагыш сатып алып,
Күгәрчен белән гөрләшеп
Утырдык бер сыйланып.

«Үзәк» дигән тукталышны
Үзәге итеп дөньяның,
И чиерттек, и чиерттек
Күңелнең зар-кылларын.

Җанны ачтык көнбагыштай,
Ап-ак икән лә төше!
«Үзәк» дигән тукталышта
Гөлдер-гөлдер күккә аштык —
Күгәрчен белән кеше.

## Ак һәм кара

Ак һәм кара — мин яраткан төсләр,
Йә караны киям, йә акны.
Йә, булмаса, тегәм күлмәгемне
Аклы-кара итеп — борчаклы.

Ак һәм кара — мин аңлаган төсләр,
Ерактан ук күргән, таныган.
Шуңа, ахры, чуар бу дөньяның
Ике төсле чагын сагынам.

Дус-дошманлы чагын, денле-денсез,
Исерек-аек чагын, көлмәгез!
Акка — ак, дип, ә карага — кара,
Яшәү рәхәт иде, белсәгез.
Саташкан аң бүген җан газаплый:
Таный алмый акны, караны.
Аералмый чынын ялганыннан
Гасырлардан өелеп калганның...

Ә өстемдә һаман ак һәм кара,
Кызыл, сары — минем төс түгел.
Йөрәк менә тибә әрнебрәк,
Бу дөньяга мин, дип, иш түгел...

## Сызлану

Тезләрем сызлый төннәрен,
Һич юк йокы күргәнем.
Тезләнеп тә яшәмәдем,
Коллыкны да белмәдем,
Ник соң сызлый тезләрем?

Төп-төз басып, горур башны
Чөеп яшәдем кебек.
Бүген көзгем челпәрәмә,
Чыккан бөкремне күреп.

Нидән болай? Кем аңлатыр?
Кем юатыр күңелне?
Тезләнеп тә яшәмәдең,
Хөрлекне дә белмәдең, дип,
Заман дәшә түгелме?

*** * ***

«Шуышырга туган оча алмый...»
Ә очасы килсә, нишләргә?
Билгеле бер тузбаш кебек әллә
Кыялардан сикереп төшәргә?

Тузбаш исән калган, безнең менә
Исән калу, ай-һай, икеле.
Күпме милләт, илен, телен җуеп,
Кыялардан аска сикерде...

Шуышырга гына тиешсез, дип
Тукый-тукый башка тумыштан,
Канатларны, аякларны бәйләп
Үткәрсәләр аңны кылычтан,

Кемнең генә очар дәрте калыр,
Кем талпыныр икән күкләргә?
«Шуышырга туган оча алмый...»
Очар өчен тудык, нишләргә?!

## Югалтулар, табышлар...

Тәүге сөюне югалттык
Табар өчен соңгысын.
Кабат яндык, кабат көйдек —
Соң булса да, уң булсын!

Югалттык зифа буйларны,
Толымнарны югалттык.
Кыска чәчле башыбызга
Сыймаслык акыл таптык.

Югалттык та, хыял бит ул —
Күктәге торна, дидек.
Учларда нәни булса да
Песнәк барга сөендек.

Җете төсләр уңа торды,
Кыңгырау тавыш — тына.
Гөл-күңелгә табыш булды
Сары да сагыш кына.

Югалттык, таптык, югалттык,
Күзләргә кереп барыш...
...Без югалтасы гомерләр —
Туар җаннарга табыш.

## Кышкы гөрләвекләр

Кышкы гөрләвекләр үзгә, үзгә.
Шатлык булып тулмый алар күзгә.
Бәхет булып күңелләргә керми,
Сөендерми бер дә, сөендерми.

Кышкы гөрләвекләр салкын, моңсу,
Кар булырга тиеш чөнки бу су.
Ак булырга тиеш, садә, назлы...
Кабул итми акыл хәтта язны,

Килсә әгәр һич вакытсыз, кинәт.
...Бата-чума хисләр ташкынына
Һәм саташкан кышның кар суына,
Сукмак эзли үз ярына йөрәк...

## Итек

Яңа итек сатып алып,
Кышны көтә башладым.
Җем-җем иткән ап-ак кардан
Вак-вак басып атлавым

Күз алдына килгән саен,
И рәхәт типте йөрәк.
Хатын-кызга бәхет өчен,
Әйтегез, күпме кирәк?

Итек тә житә икән бит
Синең кебек җүләргә,
Диярләр, беләм, берәүләр
Һәм тотыныр көләргә.
Бәлки әле, көлмәгәннәр
Көнләшеп сөртер яшен...
Килер кышның аклыгыннан,
Итегем йомшаклыгыннан
Бәхетле булып яшим!

* * *

*Илдар Юзеев истәлегенә*

Йомарланып кереп ятты күңел
Бушап калган былбыл оясына...
Йә Ходаем, хәтта тынлык үлгән,
Тугры калып Моңнар Хуҗасына.

Йомарланып кереп ятты күңел,
Ниләр уйлап, ниләр өмет итеп?
Ятим калган былбыл ояларын
Таратмасын дипме карга, сүтеп?

Йомарланып кереп ятты күңел...
Мәңгелекнең сулышында җавап —
Шагыйрь-җаннар кабат җиргә килер,
Исән оя саннарына карап,
Исән оя саннарына карап...

* * *

Күңел тәрәзәмнең пәрдәсе юк...

*Үз шигыремнән*

Күңел тәрәзәмә пәрдә алдым,
Агын ак та... Элсәм,
Калыр микән шулай ап-ак килеш
Тән каралган чакта?

Күңел тәрәзәмә пәрдә алдым,
Киңен киң дә... Элсәм,
Тараймасмы күңел, ярыйм диеп
Пәрдә киңлегенә?

Күңел тәрәзәмә пәрдә алдым,
Эләсеме? Әллә
Ак сөлгеләр итеп бүләсе дә
Өлге-өлге җырлар чигәсеме
Тормыш дигән сабантуйга?

* * *

Суган әрчегәндә еласаң да,
Җаның ачынганда еласаң да,
Төсе, тәме бер үк күз яшенең...
Күп тапкырлар шуннан файдаланып,
Җан әрнүен, борчу-кайгыларны
Аш-су бүлмәсенә мин яшердем.
Хатын-кыз бит көн дә суган турый,
Кемнәр аңлар ул нилектән елый...

* * *

Егылсаң да, югарыга егыл!
Көлсә көлсен дөнья, башын чөеп:
Күрәсезме, йолдыз тузанына
Батып ята бераү өстә (!) диеп.

Егылсаң да, югарыга егыл,
Күз яшьләрең тамсын гүя яңгыр.
Корымасын дисәң нәсел гөлең,
Йөрәк дымың җиргә биреп калдыр.

Егылсаң да, югарыга егыл,
Беркем килеп сиңа абынмасын.
Каргый-каргый тибәр түмгәк булу
Язмышыңа берүк язылмасын.

Егылсаң да, югарыга егыл!
Ай яктырак анда, кояш җылы.
Һич сер түгел, күкләр аша кыска
Ак җаннарның мәңгелеккә юлы.

Егылсаң да, югарыга егыл...

*** * ***

Кәккүк дускай, санап бирче,
Ничә ел гомер алда?
Сәгатьләр буе сана син,
Ышанам, әйдә, алда.

Икәү бергә алдыйк әле
Картлыкны һәм үлемне.
Синдәй юраучы булганда
Яшәүләре күңелле.

Берәү, икәү... унау... йөзәү...
Әй юмарт та соң үзең!
Алда мине көтә икән
Йөз язым һәм йөз көзем.

Йөз җәемдә — йөз Сабантуй,
Йөз Яңа ел иртәсе.
Йолдызларга очасым бар,
Офыкларга җитәсем.

Тик син генә, кәккүк дускай,
Туктама санавыңнан.
Үткәннәр — якты урам да,
Киләчәк — кара урман,
Туктама санавыңнан.

## Тормыш...

Тормыш — көрәш, диделәр,
Тик бер корал бирделәр.
Яхшылык җиңәр барысын,
Шуны куллан, диделәр.

Тормыш — бәхет, диделәр,
Кайнар йөрәк бирделәр.
Мәхәббәттән янып-көеп
Яшәү кирәк, диделәр.

Тормыш — шатлык, диделәр,
Керсез күңел бирделәр.
Көләч йөзле, тәмле сүзле
Бул син, сеңел, диделәр.

Тормыш авыр, диделәр,
Дус-туганнар бирделәр.
Уфтанмыйча тарт йөгеңне,
Бул син сабыр, диделәр.

Тормыш — үлем, диделәр,
Коръән Кәрим бирделәр.
Ходай каршына барырга
Бул син әзер, диделәр...

*** * ***

Йолдыз булып йолдыз сүнә,
Ә мин — гади бер кеше.
Йолдыз сүнсә, эзе кала,
Кешенең кала эше.

Тау булып тау да ишелә,
Ә мин — гади бер кеше.
Тау ишелсә, ташы кала,
Кешенең кала эше.

Диңгез булып диңгез кибә,
Ә мин — гади бер кеше.
Диңгез кипсә, тозы кала,
Кешенең кала эше.

Йолдыз, диңгез йә тауларга
Тиң булыйм дисәң, кеше,
Үзеңнән соң калсын җирдә
Изге гамәлең — эшең.

## Кышны озатканда

Ак биләвен чишкән сабыймыни,
Уянган да кышым йокыдан,
Үксеп елый, бәллүр яше тама
Бозлы керфекләре очыннан.

Юатырга сүзләр тапмый торам,
Китүләрнең беләм газабын...
Кардай ап-ак чәчәкләре булып
Син калырсың килер язларның...

## Кипкән әрем саклыйм өйдә

Кипкән әрем саклыйм өйдә,
Ә ул өемне саклый.
Яман күздән, усал сүздән,
Кара көчләрдән яклый.

Кипкән әрем саклыйм өйдә,
Әремнән әче заман.

Шәм булып әремнәр яна,
Гамь тулып үзем янам.

Кипкән әрем саклыйм өйдә,
Тыйнак гөлгә сыенам,
Коткар, диеп, тәнне-җанны
Азгын шайтан туеннан.

Кипкән әрем саклыйм өйдә,
Изге сүз, дога саклыйм.
Өемне, димәк, илемне
Кара көчләрдән яклыйм.

## Үзем белән сөйләшү

— Кемгә нәрсә исбат итәсең соң,
Яшәүләрең белән җирдә, кеше?
—Исбат итмим, бары яшим генә,
Яшим генә кояш, һава төсле...

—Кемнән нәрсә өмет итәсең соң,
Офыкларда һаман күз карашың?
—Өмет итмим, тик... беләсем килә
Бәхетемә күпме юл барасын...
—Кемгә нәрсә сатып бирәсең соң,
Кармалый гел кулың юл капчыгын?
—Сатмыйм, сатмыйм, бүләк итеп бирәм
Йөрәгемнең соңгы кыйпылчыгын...

—Кемгә нәрсә мирас итәсең соң,
Ак томандай югалырсың эреп?
—Кешелегем, рухи көчлелегем
Җырларыма калдырырмын төреп...

Беттеме инде сорауларың биреп?

## Кар яуганда

Йом күзеңне, керфегеңдә
Кар бөртеге ял итсен.
Икенчесе назлап кына
Алсу битеңнән үпсен.

Өченчесе, дүртенчесе
Кашларыңа кунсыннар,
Йөзләреңне нурландырып,
Пар йолдыздай торсыннар.

Калганнары энҗе булып
Иңнәреңә сибелсен.
Яңа яуган садә карга
Баштанаяк төрен син...

## Су буенда

Күңелемдә бушлык барын
Җаны белән сизгәндәй,
Өзеп-өзеп бер кош сайрый
Моң тутырам дигәндәй.

Мең ризамын бу бүләккә,
Рәхмәт былбыл-тирәккә,
Шул моңнардан ярылмыйча
Түзә алган йөрәккә...

## Бер картлыкта, бер яшьлектә...

Пар каеннар серләшкәндә
Яфракка яфрак куеп,
Утырганың хәтеремдә
Сак пышылдаудан оеп.

Күзең йомык, иреннәрең
Джаконда көнләшерлек.
«Тукта, мизгел! Син — гүзәл!» — дип
Хәл таптым эндәшерлек.

Сискәнеп дерелдәп куйды
Шулчак бәрхет керфекләр.
Ал битеңнән тәгәрәде
Көмештәй саф бөртекләр...

Тукта, яшьлек! Син — гүзәлсең!
...Син — мәзәксең, и картлык!
Ике каен арасында
Йөрмә, зинһар, адашып.

## * * *

Һәркемгә дә бүлгән икән
Тормыш йөге-чүмәлә.
Кем иңендә, ә кем инде
Йөрәк белән күтәрә.

Иңнәргә, ай, җиңел түгел,
Йөрәккә — әйтәсе юк.
Бәхет дигән елгыр атның
Йөгәне, тәртәсе юк.

Чаба гына гомер буйлап,
Тоттырмый, дулап-дулап.
Ташлап булмас йөк астында
Җан бара авыр сулап.

Тәннәр сызлый, йөрәк кага,
Иреннәрдә тоз тәме...
Бәхет атын җиксәң, язмыш,
Миңа таба бор, яме?!

## Миләш белән каен

Кояшның алсу йөзеннән
Әллә соң өзелгәннәр —
Алма-алма кызылтүшләр
Каенга тезелгәннәр.

Тын да алмый сылу каен,
Уңмасын тере бизәк.
Кылтайчык миләш кызының
Күреп калуы кирәк.

Анда гына күлмәк, имеш,
Анда гына ут-ялкын.
Үзенә каратып торды
Кыш буе урман халкын.

Менә хәзер татысын ул
Бар тәмен көнләшүнең,
Башкалар татыган кебек
Әчесен миләшенең...

Кояшның алсу йөзеннән
Әллә соң өзелгәннәр —
Алма-алма кызылтүшләр
Каенга тезелгәннәр.

Ул елмая, мин кушылам,
Яз хәбәр биргән чаклар.
Берсен-берсе күзли-күзли,
Матур бизәк эзли-эзли,
Дөньяны ямьгә төрәләр
Нечкәбил асыл затлар!

## * * *

Исте җилләр ил эченнән...

*Дәрдемәнд*

Асты өскә ник, дисәм —
Ил эченнән җил искән.
Байлыкларны, халыкларны
Өермә җилләр кискән.

Кем аягүрә ауган,
Кем качып-посып калган.
Хәйләкәр һәм куркаклардан
Безнең буын баш алган.

Куркакка соң нигә тел?
Дәшми-тынмый тора гел.
Нигә ил хәйләкәргә?
Тик җай булсын яшәргә.

Ил эченнән җил искән,
Халкымның җанын кискән...

* * *

Яхшылыкның алтын орлыкларын
Җилгә түгел, җиргә сипсә һәркем,
Миллион еллар тагын, миллион еллар
Гүзәл чәчәк булып атар һәр көн.

Чын мәхәббәт тулы саф йөрәген
Хискә төреп күккә чөйсә һәркем,
Миллион еллар тагын, миллион еллар
Йолдыз тулып балкып янар һәр төн.
Акыл көчен изге эшкә җигеп,
Армый-талмый хезмәт итсә һәркем,
Миллион еллар тагын, миллион еллар
Әйләнер Җир күчәрендә... бәлкем.

## Урын җитәрлек

Кырлар-урманнар, болын-тугайлар...
Бу киңлекләргә исең китәрлек!
Әй сез, кешеләр, ни соң бүләсез?
Кояш астында урын җитәрлек.

Ачулы караш, сүзләр ятьмәсе,
Төйнәлгән йодрык — бар да чишәрлек.
Әй сез, кешеләр, нәрсә бүләсез?
Кояш астында урын җитәрлек.

Туу һәм үлем — гомер ярлары,
Мизгел эчендә очып үтәрлек.
Әй сез, кешеләр, ни соң бүләсез?
Кояш астында урын җитәрлек.

Җир куенында урын җитәрлек...

## Яңгырдан соң

Нәни генә күлләвеккә
Ярты күк йөзе сыйган.
Яңа сауган сөттәй җылы
Болытта басып торам.

Туфлиләр ята чирәмдә,
Маэмай уйный тирәмдә.
...Әллә ниләр бирер идем
«Кызым, чумма!» дигәнгә.

«Кызым, чумма!» дигәнгә лә,
Әрли-әрли сөйгәнгә,
Яңгыр тамчылары юган
Чәчләремне үргәндә...

Туган йортым ишегалды,
Сиңа бар дөньям сыйган!
Яңа сауган сөттәй җылы
Мизгелдә басып торам.

* * *

Күкрәүләре белән истә
Җәйләре балачакның.
Бигрәкләр еш уйный иде
Күкләрдә яшен-камчы.

Утлы баулардан ишелгән
Ул камчыдан куркулар,
«Сөбханалла, машалла...» — дип
Тын гына яшь йотулар
Юкка гына булган юкса
Яшьлектә, балачакта.
Әнинең яшен үткәргеч
Йөрәге торган сакта.

Ак җаны торган сүндереп
Көйдергеч язмыш угын,
Тидерми миңа ялкынын,
Тидерми миңа бозын...

Күкрәүләре белән истә
Кала гомер хәзер дә.
Яшен үткәргеч тик үзем —
Утлар ява бәгырьгә...

* * *

Рәхмәт инде кошларга
Безнең белән кышларга
Туган җирдә калган өчен,
Дидем дә мин өшеп куйдым
Кар өстенә оя корган
Һәрбер кара карга өчен...

Рәхмәт инде кыз-улларга,
Тугры булып ыруларга,
Туган илдә калган өчен,
Дидем дә мин әрнү тойдым
Заман җиле өтеп торган
Һәрбер газиз бала өчен...

## Тагын бер кат сөю турында...

Бу дөньяга без килгәнбез, беләм,
Сайрар кошлар җырын тыңлар өчен,
Сөйгәннәрне өзелеп сагынганда,
Шул кошларга кушылып җырлар өчен.

Бу дөньяга без килгәнбез, беләм,

Болыннардан чәчәк өзәр өчен,
Чәчәкләрнең иң гүзәлен сайлап,
Сөйгән ярның түшен бизәр өчен.

Бу дөньяга без килгәнбез, беләм,
Дулкыннарга ятып йөзәр өчен,
Йомшак дулкын булып, назлап кына
Бердәнберне кочып үбәр өчен.

Бу дөньяга без килгәнбез, беләм,
Тик бер хистән янып-көяр өчен:
Гашыйк җанны күккә чөя-чөя
Сөяр өчен, бары сөяр өчен!

# Эчтәлек

**Ике гасыр баласы мин...**


Кадерен беләм ........................
«Язмыш җиле, шөкер, минем яклы...» ..........
«И түбәннән агылалар бу болытлар...» .........
Җыр тыңлаганда ......................
Сандыгымда өч күлмәк ..................
«Яз башында шыткан үлән сыман...» ..........
Дөнья .............................
Яшим икән әле! .......................
«Сиңа гына кирәкме бу дөнья?..» ............
«Үз телемдә сүз әйтимче...» ................
Шигырь туган көндә ....................
Мин — гашыйк .......................
«Кышлар озын булган саен...» ..............
«Нурларында таңның коенмасаң...» ...........
«Кыштыр-кыштыр...» ...................
Бәхет .............................
Тәрәзәмә яңа пәрдә элдем .................
«Болыт йөзә, болыт ага, дибез...» .............
Күңел эзли ..........................
«Талчыбыкны бөгә-тезә...» ................
«Йөгермәдем, ашыкмадым бер дә...» ..........
«Качышлы уйныйм...» ...................
Ромашкалар .........................
Таган ..............................
Бер үпкәм юк ........................
«Ничә тапкыр җиргә килдең, җаным?..» .........
«Тормыш юлы — ефәк җеп ул...» ............
«И кешеләр, бармы шатлыгыгыз?..» ...........
Җәйге уйлар .........................
Өшү ..............................
Исәнлектә күрешергә язсын ................
Балалар уенын күзәткәндә ................
«Җир — Кояшның кызы...» ................
«Бер хакым юк халкым телсез диеп...» ..........
Ике гасыр баласы мин ...................
«Шагыйрь күңеле...» ....................
«Бураннарын кышның яратканнар...» ..........
Ана телем ...........................
Яфрак оча ..........................
«Ил казаны кайный...» ..................
«Бишекләрдә тирбәлмәгәч...» ..............
«Базарларны җенем сөйми...» ..............
«Каравыл! Талыйлар...» ..................
«Кара күзлек күзендә...» .................
«Күңелемдә — таулар биеклеге...» ...........
«Берәм-берәм буар елан йота...» .............
«Казанны күрергә барабыз...» ..............
«Чишмә — җирнең шатлык яше...» ...........
Җирем минем ........................
«Кояшлы кар ява...» ....................
Эт язмышы ..........................
«Кызган мунча ташы кебек...» ..............

«Сугыш бара илдә...» ...................
«Бөркетләр тауга оялый...» ................
Әйтә алырбызмы? .......................
Танышыма ..........................
Китә алмыйм .........................
Җилләр иле .........................
«Сандыгым юк...» .....................
Язгы буран ..........................
Әйләнәм дә кайтам .....................
«Китәргә җыенган кошлар...» ..............
Туган йортым ........................
«Капка keләсен ачарга...» .................
Язгы кояш ..........................
«Сукыр лампа яктысында...» ................
«Алтын белән таш ватасың!..» ...............
Кычыткан ...........................
Кайту .............................
«Кышның аяз кичләрендә...» ..............
Йөрәк мичем .........................
Дәвам .............................
Рәшә .............................
«Сабантуйда һәрчак бүләк ала...» ............
Кызыма ............................
Күлмәк тегәм .........................
Авылыма алып кайтыр юл .................
Кара куык ..........................
«Сагынасыңмы авылыңны, әни?..» ...........
Адашканнар .........................
Күзге бишек җыры .....................
Кайталмадым ........................
Яшьлек дустыма .......................
Яшьлек ............................

**Күңел күзе җитмәс ераклык юк...**

«Кыш әллә елап китәме...» ................
Гомер йомгагым .......................
Гомер сорыйм ........................
«Тау белән тау да очраша...» ...............
Тузганак ...........................
«Таулар биек, текә, диеп...» ................
«Ярый әле җилләре бар...» ................
«Эңгер-меңгер...» ......................
Сер сандыгым ........................
Үз-үземә теләк .......................
«Һәркем белгән, аңлаганны...» ...............
«Күңел күзе җитмәс ераклык юк...» ...........
Хыял белән хушлашу ...................
Үтә гомер ...........................
Тамаша ............................
Картлык ............................
Тормыш арифметикасы ..................
«Туйлар узды, туннар тузды дигән...» ..........
«Кеше күрмәгәндә биеп...» ................
«Талларга кунып сайрый кош...» ............
«Ачулы чагыңны уйласам...» ...............
«Кайгыларга төренгән бар...» ...............
Танымыйм ..........................
Энә һәм Җеп .........................
«Идән җәймәседәй...» ...................
«Бер карага, бер сарыга буйыйм...» ...........
Күңел .............................
«Җил иркәли сөеп чәчләремнән...» ...........
«Ак юл булып бәхет сузылды да...» ...........
Ташлама мине, мәхәббәт! ..................
«Түздем...» ..........................
«Тоткынлыкта иде хисләр...» ...............
Беренче мәхәббәт ......................
«И салмак ла адымнарым...» ...............
«Челпәрәмә килде бәллүр дөнья...» ...........
«Кар базыдыр синең акыл...» ...............
Кар кызы ялваруы .....................
«Сөю» дигән чолганышта калсам ............

«Алма коя итәгемә август көне...» ............
Гашыйк булыйк .......................
Тану .............................
«Ак томанга төренеп атты...» ...............
Буранда ............................
«Ничә сүтеп, чәчләремне...» ................
«Тән ярасын төзәтүче...» .................
«Әйткәннәре өчен үкенәбез...» ..............
Яз башы ............................
«Әрсез тамчы түгел шул мин...» .............
«Башланды көзге явымнар...» ..............
«Нарат урманында көзләр яшел...» ...........
«Туфлиемә ияреп кергән...» ...............
Табигать, өйрәт яшәргә... .................
Үкенеч .............................
«Нинди төз буй! Нинди мәһабәт сын!..» .........
Миләш җыям ........................
Беренче буран ........................
Карлар ява ..........................
Кышкы рәшә .........................
«Болытлар куера күкләрдә...» ..............
«Карны чәчәккә тиңлибез...» ...............
Каен белән серләшү ....................
Күкрәү ............................
«Тын бакчада сихри иртә...» ...............
Яз алдыннан .........................
«Ун тәңкәгә ике чәркә...» .................
Ак һәм кара .........................
Сызлану ............................
«Шуышырга туган оча алмый...» .............
Югалтулар, табышлар... ..................
Кышкы гөрләвекләр ....................
Итек .............................
«Йомарланып кереп ятты күңел...» ...........
«Күңел тәрәзәмә пәрдә алдым...» .............
«Суган әрчегәндә еласаң да...» ...............
«Егылсаң да, югарыга егыл!..» ...............
«Кәккүк дускай...» .....................
Тормыш... ..........................
«Йолдыз булып йолдыз сүнә...» .............
Кышны озатканда ......................
Кипкән әрем саклыйм өйдә ................
Үзем белән сөйләшү ....................
Кар яуганда .........................
Су буенда ..........................
Бер картлыкта, бер яшьлектә... ..............
«Һәркемгә дә булгән икән...» ................
Миләш белән каен ......................
«Асты өскә ник, дисәм...» .................
«Яхшылыкның алтын орлыкларын...» .........
Урын җитәрлек .......................
Яңгырдан соң ........................
«Күкрәүләре белән истә...» ................
«Рәхмәт инде кошларга...» ................
Тагын бер кат сөю турында... ...............

Литературно-художественное издание

**Якупова** Сирень Мохиббуловна

**Тайна жизни**

Казань. Татарское книжное издательство. 2008

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Якупова** Сирень Мөхибулла кызы

# Яшәү сере

Мөхәррире *Ф.И.Фәтхетдинова*
Рәссамы *А.Р.Хисмәтова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *Л.З.Шиһапова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 7.07.2008. Форматы 70г90 1/32.
Шартлы басма табагы 4,68. Шартлы буяу-оттиск 4,97.
Нәшер-хисап табагы 4,3. Тиражы 1000 д. Заказ Т-796.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

http://tatkniga.ru
E-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066.
Казан, Декабристлар урамы, 2.